ҖИР ТӘМЕ

Чирмешән районында агрофирма басу-кырларын бүләләр

> 5

ӨЗЕЛМӘСЕН ЧӘЧӘК

Балалар ни сәбәпле тормыштан ваз кичә?

> 15

МИЛӘҮШӘ ХӘБЕТДИНОВА:

«Исәнбәт архивындагы бик күп нәрсәгә безнең тешебез үтми»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 65 (28838) | Җомга | 13 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КАЗАН КАЙМАСЫ

ТЫЛДАГЫ БАТЫРЛЫККА – 80 ЕЛ

Сугыш елларында фронтта гына түгел, Җиңүне якынайту өчен тылда да аяусыз көрәш бара. Гомуми озынлыгы 331 чакрымны тәшкил иткән, Иделнең уң як ярында ярымбоҗра рәвешендә төзелгән Казан каймасы – шуның бер мисалы.

> 16

Ишетми калмагыз

Татарстанда күпбалалы ата-аналарга тән тиресен бушлай тикшертү мөмкинлеге ачыла. Кирәк булса, яман шешләрне алдан ачыклау өчен, цифрлы диагностика үткәреләчәк. 16 майдан республикада «Меланома-Стоп» акциясе башлана. Проектны Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова тәкъдим иткән. Казанда – «Клиника СЛ», Чаллыда Республика клиник онкология диспансеры филиалы табиблары кабул итәчәк. Шулай итеп, һәр шәһәрдә йөзләп гаиләнең сәламәтлеген тикшерү күздә тотыла. Тикшерү барышында табиб яман шеш түгелме дип шикләнсә, өстәмә тикшерү билгеләнәчәк.
Моннан тыш Татарстанда яшәүчеләр тәндәге миңнәрен табибка бармыйча гына тикшертә алачак. Моның өчен миңне, янәшәсенә линейка куеп, якыннан фотога төшерергә кирәк. Шуннан соң фотосурәтне һәм элемтәгә керү өчен кирәкле мәгълүматларны электрон адреска (oncort16@yandex.ru) юлларга. Табиб-онкологлар һәр фотосурәтне игътибар белән өйрәнәчәк. Кирәк булса, белгечкә өстәмә тикшерүгә җибәрәчәк.

Ташламалы ипотеканы 2022 ел азагына кадәр озайту һәм ипотека ставкасын 9 процентка калдыру гаиләләргә зур ярдәм булып кына калмыйча, төзелеш тармагын һәм башка катнаш тармакларны җанландырып җибәрәчәк. Россия Президенты Владимир Путин әйтүенчә, акча-кредит сәясәтенең йомшаруы һәм Россия банкының төп ставканы 14 процентка калдыруы нәтиҗәсендә шундый карар кабул итүгә ирешелгән. «Май аеннан 9 процентлы ставка буенча ташламалы ипотека алырга мөмкин. Фатирлы булырга, торак шартларын яхшыртырга ниятләүчеләр өчен бик кулай булачак бу», – диде дәүләт башлыгы.

Татарстанга бюджеттан 3,86 миллиард сум күләмендә кредит бирүгә заявка хупланган. Россия төбәкләрен үстерү буенча Хөкүмәт комиссиясе президиумы утырышында шундый карар кабул ителгән. Бу хакта Татарстан Президенты матбугат хезмәте хәбәр итә. Шулай итеп, республикага Алексеевск – Әлмәт автомобиль юлын төзүгә бәйле рәвештә территорияләрне үстерүгә кредит биреләчәк. Проектта 719 мең кв. метр торак мәйданын файдалануга тапшыру һәм 5358 эш урыны булдыру күздә тотыла.

Соңгы өч айда Татарстанда яшәү өчен мөһим булган дарулар 1,9 процентка кыйммәтләнгән. Бу хакта Росздравнадзорның Татарстан идарәсе башлыгы Любовь Шәйхетдинова белдерде. Билгеле булганча, Россиядә сатыла торган 38 мең даруның 700–800е генә шундый препаратлар төркеменә керә. Белгеч сүзләренә караганда, республика даруханәләрендә дару бәясе генә түгел, сыйфаты да контрольдә тотыла. Идарә ел башыннан бирле даруханәләрдән 349 дару үрнәген сайлап алып, аларга тикшерү уздырган. Тикшерү барышында 4 төрле препаратның тиешле таләпләргә туры килмәве ачыкланган. Алар сатудан алынган. Моннан тыш идарә дарулар сату турында шикле игъланнар урнаштырылган 700ләп сайтны юкка чыгарган.

ЯРДӘМ ВАКЫТЫНДА КИРӘК

Чарасы булганда, файдаланасы, тотрыклы эшләүне тәэмин итәсе. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республика сәнәгатен үстерү буенча киңәшмә уздырды. Чара Казан дары заводында үтте.

Киңәшмә алдыннан Рөстәм Миңнеханов дары заводының укыту үзәге эше белән танышты. Әлеге үзәк заманча җиһазлар һәм махсус тренажерлар белән тәэмин ителгән. 2021 елда бирегә 2011 кеше белем алган. Шул исәптән тармакның башка предприятиеләре хезмәткәрләре дә.

– Хәзергә төп максат – предприятиеләрнең тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү һәм үстерү, – диде Татарстан Президенты утырышта. – Предприятиеләр икътисади басым һәм чикләү шартларында эшләргә мәҗбүр. Федераль һәм республика дәрәҗәсендә икътисадның реаль секторына ярдәм итү буенча кайбер чаралар кабул ителде. Һәр предприятие вакытында ярдәм алырга тиеш.

Тагын бер мөһим юнәлеш – хезмәт коллективларын саклау. Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, бигрәк тә оста белгечләрне эштә калдыру кирәк. Бу җәһәттән хәлләр зарланырлык түгел дип ышандыралар. Рөстәм Миңнеханов завод-предприятие җитәкчеләрен ярдәм итү чараларыннан файдаланырга чакырды. Татарстан Президенты импортны алмаштыру һәм кооперация сорауларына да игътибар итте.

– Җитештерүчеләргә яңа кооперация элемтәләре урнаштыруда ярдәм итәргә кирәк. Татарстанда импортны алыштыручы сәнәгать үрнәкләренең яхшы мисаллары бар инде, – диде Рөстәм Миңнеханов һәм бу җәһәттән «Түбән Кама Нефтехим», Менделеевскидагы заводны телгә алды.

tatarstan.ru

Президент башка илләр белән мөнәсәбәтләрне ныгыту мәсьәләсен дә күтәрде. Аерым алганда, сүз илнең бүтән төбәкләре һәм ЕврАзЭС илләре (Белоруссия, Казахстан, Үзбәкстан һәм башкалар) турында барды.

Утырыш вакытында Рөстәм Миңнеханов күтәргән тагын бер мөһим мәсьәлә төбәктә конструкторлык бюроларын торгызу һәм фәнни мәктәпләр белән хезмәттәшлек турында булды. Президент ассызыклаганча, яңа проектларны тормышка ашыру өчен кирәк алар.

Утырыш ахырында Татарстан Президенты 14 предприятиегә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» дигән мактаулы исем тапшырды.

– Илебез тарихында катлаулы чорлар булды. Без һәрвакыт куелган максатларга ирештек. Бөек Ватан сугышы елларында илебез Җиңүгә безнең сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләре дә зур өлеш керт-те. Хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге традицияләре хәзер дә, киләчәктә дә яшь буынга тапшырылыр дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов бүләк ияләрен котлаганда.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәннәре, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирергә:

«Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводына;

«Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенә;

«Казан моторлар төзү-житештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенә;

«Казан оптика-механика заводы» акционер җәмгыятенә;

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенә;

«Химия продуктлары дәүләт фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесенә;

«Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенә;

«Мелита» Татарстан мех сәүдә-сәнәгать җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә;

«Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыятенә;

«Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә;

«Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесенә;

«Казан электр техникасы заводы» акционер җәмгыятенә;

Казан «Электр приборлары» заводы ачык акционер җәмгыятенә;

«Вакууммаш» акционер җәмгыятенә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 07 май № ПУ-321

БЕРЕНЧЕСЕ – БУАДА

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга Татарстандагы кебек ярдәм Россиянең башка бер генә төбәгендә дә юк. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Буада авыл хезмәтчәннәренең эшмәкәрлек активлыгын үстерү мәсьәләләре буенча үткәрелгән зона-семинар киңәшмәсендә шулай диде.

Зона киңәшмәсенең быел әле беренче тапкыр гына уздырылуы. Май аенда Кукмара, Мөслим һәм Чирмешән районнарында да шундый ук киңәшмәләр үткәреләчәк. Зона киңәшмәләре республикада инде 2010 елдан бирле уздырылып килә. Бу эш, Татарстан Президенты боерыгы буенча, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендә алып барыла.

Киңәшмә алдыннан Фәрит Мөхәммәтшин район хакимияте башлыгы Ранис Камартдинов белән ремонттан соң ачылган район үзәк хастаханәсендә гериатрия бүлмәсендә булды. Өлкән яшьтәгеләргә сәламәтлекне кайгырту өчен барлык шартлар тудырылган. Бүлмә медицина җиһазлары белән тәэмин ителгән, белгеч-гериатр эшли.

Фәрит Мөхәммәтшин «Хәтер бакчасы» акциясенә дә кушылды. Парламент башлыгы Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаган якташларыбызның батырлыгы истәлегенә шәһәрнең бер паркында каштан үсентесе утыртты. Бөтенроссия акциясе бу көннәрдә илнең күп кенә шәһәр-авылларында үткәрелә.

Зона киңәшмәсендә республиканың 8 районы хакимияте һәм авыл җирлеге башлыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм гаилә фермалары җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы кооперативлары вәкилләре катнашты. Анда фермер хуҗалыкларының эш йомгаклары буенча тәфсилле сөйләшү булды. Хәзерге вакытта республикада 470 меңнән артык шәхси ярдәмче хуҗалык, 4 меңнән күбрәк фермер хуҗалыгы һәм 300дән артык авыл хуҗалыгы кооперативы эшләп килә. Һәр ел саен Татарстанда авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысыннан артыгын шәхси хуҗалыклар һәм фермерлар җитештерә.

Фәрит Мөхәммәтшин, киңәшмәне ачып, узган елда агросәнәгать комплексының, корылыкка карамастан, яхшы нәтиҗәләргә ирешүен билгеләп үтте.

Бүген исә, ил икътисадына моңарчы күрелмәгән санкция басымы төшү шартларында, яңа кыенлыклар пәйда булды. «Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең тырышлыгы белән кибетләр һәм складларда беренче чиратта кирәкле барлык товарлар запасы булдырылды, бәяләрнең котырып үсүе туктатылды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздыру халык өчен бик файдалы һәм отышлы булды. Хәзерге вакытта ваклап сату өлкәсе тотрыкланды, кибетләр гадәттәгечә эшли».

Парламент башлыгы искәртүенчә, азык-төлек иминлеге мәсьәләләрен аерым игътибар үзәгенә алырга кирәк. Татарстан терлекчелек продукциясе белән үз-үзен тулысынча тәэмин итә. Әмма кайбер районнарда терлекләрнең баш саны кимү очраклары бар. «Шундый дәүләт ярдәме булганда, мондый хәлгә юл куярга ярамый», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Шәхси хуҗалыкларга дәүләт ярдәменә килгәндә, республикада бу юнәлеш һәрвакыт өстенлекле булып килә. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, һәр ел саен кече хуҗалыкларга грант һәм субсидияләр рәвешендә 2 миллиард сумнан артык акча бирелә. Быел республикада агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме максатында барлыгы 13 миллиард сумнан артыграк акча җибәреләчәк.

tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе хуҗалыклар җитәкчеләрен дәүләт ярдәме программаларында активрак катнашырга чакырды. «Бюрократик киртәләр кимеде, хәзер барысы да үзегездән тора, – дип мөрәҗәгать итте парламент башлыгы фермерлар һәм авыл җирлекләре башлыкларына. – Эшегез өчен өстәмә мөмкинлекләр эзләргә кирәк. Яңа мөмкинлекләрне өйрәнегез, эшмәкәрләр белән урыннарда аңлату эшләре алып барыгыз, аларга гаризалар рәсмиләштерүдә ярдәм итегез».

КӨТЕЛГӘН ВАКЫЙГА

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮГӘ 1100 ЕЛ ТУЛУНЫ НИЧЕК БӘЙРӘМ ИТӘЧӘКБЕЗ?



tatarstan.ru

Коръән языла, мәчеткә таш салына, фильм күрсәтелә, эшлекле аралар якыная. Татарстан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп узарга әзерләнә. Санаулы көннәр калган вакыйга алдыннан журналистларга башкарылган эш һәм буласы чаралар турында сөйләделәр.

1100 еллыкка 150дән артык чара

Әлбәттә, алар барысы да бер көндә оештырылмый. 1100 еллыкны ел дәвамында билгеләп узачакбыз. Төгәлрәк әйткәндә, бу елның гыйнварыннан билгеләп үтә башладык инде. Төп чаралар исә май аена тәгаенләнгән. Шулар турында Татарстан вице-премьеры Васил Шәйхразыев сөйләде.

– Тарихи көнгә бәйле чаралар ел дәвамында, Татарстанда гына түгел, ил күләмендә узачак. Федераль һәм республика планында 150ләп чара каралган. Күпчелек чаралар республиканың Диния нәзарәте, Мәдәният министрлыгы тарафыннан оештырылачак, – диде ул.

Төп чаралар планына күз салсаң, алар, билгеле, Болгар җирендә узачак. 21 майда бирегә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган зур тантана көтелә. Ул 11 сәгатькә билгеләнгән. Гадәттәгечә, намаз уку булачак, аннан соң кунакларга театральләштерелгән тамаша күрсәтеләчәк.

Шушы ук көнне 1100 еллыкка махсус атап чыгарылган почта маркасына мөһер сугу да каралган. Анысы Болгар ислам академиясендә узачак.

Бәйрәм көнендә Ак мәчет һәм Казан Кремлендә яктылык тамашасы да күрсәтелер дип көтелә. Тарихи вакыйга матур итеп заманча технологияләр кулланып сурәтләнәчәк.

«Милли тормыш һәм дин» XII Бөтенроссия татар дин әһелләренең форумы да 1100 еллыкны бәйрәм иткән көннәргә туры киләчәк. Аңа Россиянең 76 төбәге һәм дөньяның 7 иленнән 1100ләп дин әһеле чакырылган.

Тантаналы көнгә бер көн кала исә Казанда Җәмигъ мәчетенең нигезенә беренче таш салыначак. Һава торышының нинди булуына карамастан башкарылачак бу эш. Территорияне инде әзерләгәннәр. «Таш салу көндезге сәгать бергә тәгаенләнгән. Бу таш кабатланмас истәлекле вакыйганың төп асылын саклап калачак һәм тарихи истәлекне киләчәк буыннарга тапшырачак. Нинди генә һава торышы булса да, чара узачак. Мәчет 10 мең кешене сыйдырачак. Бина каяндыр күчермәсен алып, кайсыдыр мәчеткә охшатып төзелмәячәк, аның макетына конкурс игълан ителде. Макет сайланганнан соң проект эше башланып китәчәк. Яңа мәчеткә исем бирү турында фикерләрне дә күзәтеп торабыз. Бу эштә халыкның активлыгы да мөһим», – диде вице-премьер.

Әһәмиятле вакыйганы билгеләп узу моның белән генә чикләнми, билгеле. Өстәрәк язуыбызча, министрлык, Диния нәзарәте тарафыннан күп кенә кызыклы чаралар тәкъдим ителәчәк. Алар арасында фильм, күргәзмә, опера, махсус спектакль, фестиваль-бәйгеләр дә бар.

Хәләл турында сөйләшик

Бу көннәрдә эшмәкәрләргә дә, рәсми затлар өчен дә фикер алышыр мәйданчык булачак. 19 майда Казанда «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты узачак. Чара кысасында нәрсәләр оештырылачагы турында журналистларга Татарстанның инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Инсаф Галиев сөйләде.

Саммитның төп эшлекле программасы хәләл, икътисад, ислам финанслары, экспорт үсеше, инвестиция һәм эшкуарлыкка багышланган. Чара кысасында Russia Halal Expo күргәзмәсе (быел мәйданын ике мәртәбә арттырганнар. – **Авт.**), машина төзелеше форумы, World Halal Day (Бөтендөнья хәләл көне), MuslimQuiz уены оештырылачак. Саммитта 17 сессия узачак.

Чара халык өчен дә ачык итеп үткәреләчәк. Инсаф Галиев аңлатканча, Казаннан саммит узачак «Казан Экспо» үзәгенә бушлай автобуслар йөриячәк. Күргәзмә 3 көн дәвам итәчәк.

Монысы инде катнашырга теләк белдергән эшмәкәрләр колагына: Инсаф Галиев искәрткәнчә, саммитка теркәлү вакыты 15 майга кадәр озайтылган. Катнашырга теләүчеләр күп булганга шулай эшләгәннәр. Хәзергә чарада катнашырга теләк белдереп 1,6 мең кеше теркәлгән. Бу – дөньяның 55 иленнән һәм Россиянең 42 төбәгеннән катнашучылар. Оештыручылар сүзләренчә, аларның саны 5 меңгә кадәр җитәргә мөмкин. Саммит 1100 еллыкны бәйрәм итү кысасында Болгарга сәфәр белән тәмамланачак.

Тәҗрибә уртаклашу

«Россия – ислам дөньясы» стратегик төркеменең ел саен уза торган утырышы быел Казанда 20 майда оештырыла. Ул да Болгарда ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу кысасында үтә. Татарстан Президенты ярдәмчесе Газинур Бакиров әйтүенчә, утырышка дөньяның төрле почмакларыннан 100 катнашучы киләчәк. Барысын да бер нәрсә: Россиянең этномәдәни күптөрлелеген һәм милләтара татулыкны саклауда тәҗрибәсе кызыксындыра.

– Утырыш Казан Ратушасында узачак. Алжир, Сенегал, Мисыр, Индонезия, Иордания, Төркия, Тунис һәм башка илләрдән кунаклар көтәбез. Күпчелеге онлайн кушылачак. Халыкара вазгыятьнең киеренке булуына карамастан, төркем эшен дәвам итә һәм элемтәләрне үстерә, – дип аңлатты Газинур Бакиров.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Ныгысын өчен дуслык

11–13 майда Казанда Чечен Республикасының мәдәният министры Айшат Кадыйрова катнашында чечен мәдәнияте көннәре уза. Әлеге чараның әһәмияте, максат һәм бурычлары нидән гыйбарәт?

Тәҗрибә алмашу, Чечня белән Татарстан арасындагы дуслыкны ныгыту, мәдәният белән таныштыру. Чечнядан килгән делегация үз алдына әнә шул бурыч һәм максатларны куйган. «Бүген төбәкләр һәм халыклар арасындагы дуслыкны ныгыту аеруча мөһим. Илдәге вазгыятьне исәптә тотып, безгә бер телдә сөйләшергә кирәк. Бу очракта ул – мәдәният теле», – диде Айшат Рамзан кызы Казандагы чечен мәдәнияте көннәре турында.

Кунаклар буш кул белән килмәгән. Әйтик, 12 майда «Казан Кремле» музей-тыюлыгында Чечня музееның «XIX–XXI гасыр Чечен Республикасы сәнгате» күргәзмәсе ачылды. Башкала халкы һәм кунаклары 13 июньгә кадәр 100дән артык сәнгать әсәре белән таныша алачак. Арадарында чечен рәссамнарының төрле стиль һәм жанрда ясалган картиналары, хатын-кыз һәм ир-атларның традицион киемнәре, зәркән эшләнмәләр, милли орнаментлы келәмнәр һәм башкалар бар. «Биредәге һәр экспонат чечен халкының рухы һәм тарихи үзенчәлекләре турында сөйли», – диде Чечен Республикасы музееның генераль директоры Залина Мамаева күргәзмә ачылышында.

Шушы ук көнне Грозный шәһәренең Лермонтов исемендәге рус драма театры Камал театры сәхнәсендә «Волки» спектаклен тәкъдим итте. Әлеге әсәр – Сталин репрессияләре вакытында Чечня тауларында качып яткан кешеләр турында.

Казандагы чечен мәдәнияте көннәре филармониядәге Чечня сәнгать осталары концерты белән тәмамланачак. Кичәдә Шахбулатов исемендәге Чечня дәүләт филармониясенең халык музыкасы ансамбле, «Вайнах» бию ансамбле һәм балалар симфоник оркестры чыгыш ясавы көтелә.

– Быел бездә Казанның китерелгән Коръән китаплары күргәзмәсе узды. Без дә, үз чиратыбызда, Казанга килеп, үз мәдәниятебез белән таныштырырга булдык, – диде Айшат Кадыйрова журналистлар белән очрашуда. Аның сүзләренчә, быел Чечен Республикасы төзелүгә 100 ел тула, һәм бу – чечен мәдәнияте турында сөйләү өчен тагын бер сәбәп.

Ул шулай ук Казан шәһәрен күреп, милли ризыкларыбызны татып, таң калганын да яшермәде.

«Минем өчен бу аралашу бик мөһим. Безнең халыкларны берләштерүче уртак башлангыч бар, ул – Коръән. Дөньяга карашыбыз да, традицияләребез дә нәкъ менә аңа бәйләнгән. Миңа калса, мәдәният – безнең халыкларга алга атларга, киләчәген төзергә ярдәм итә торган мохит. Киләчәктә Чечен Республикасы белән хезмәттәшлек итәр өчен ниятләребез зурдан», – диде Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова.

Очрашуга Чечен Республикасының туризм буенча министры Мөслим Байтазиев та килгән иде. «Безнең уртак якларыбыз хәйран күп. Ике республиканың әләмнәре дә охшаш бит. Бүген без халыкларның берләшүен сүздә генә түгел, гамәлләр аша да күрсәтергә тиеш», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татар-информ»

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Хәтер

Беркөнне телевизордан Ригадагы хәлләрне хәйран калып карап утырдым. Латвияне фашистлардан азат итү өчен барган сугышларда һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл-обелиск янындагы чәчәкләрне бульдозер белән эттереп, чүп контейнерларына ташлаганнарын күрсәттеләр. Кемгә тия ул чәчәкләр, кемгә тия ул һәйкәл? Кайчандыр союздаш республика булган Латвиянең тарихка мөнәсәбәте ни өчен шулай кискен үзгәрде? Ни өчен бөтен Европа илләре диярлек безгә артлары белән борылды? Европаны фашистлардан азат итү өчен барган бу зур орышта миллионлаган улларын югалткан илне ни өчен «агрессор» дип атый башладылар? Әлеге сорауларга анык кына җавап бирү кыен һәм тарихта зурлап казынырга да җыенмыйбыз. Мине фәкать тарихи хәтернең шулай тиз үзгәрүе генә гаҗәпләндерә. Ни өчен кичәге «ак» бүген карага, ә кичәге «кара» бүген акка әйләнде соң? Моңа шактый ук дәрәҗәдә үзебез дә гаепле.

Бәйрәм көннәрендә якын дуслар белән бер-беребезне котлаштык. Шуларның берсе – запастагы полковник Рөстәм Гомәров элемтә техникумында укыта. Патриотик тәрбия буенча зур эш алып бара ул. «Кайнар нокта»ларда да катнашкан офицер буларак, мәктәпләргә очрашуларга да чакыргалыйлар үзен. Бәйрәм арасында Казанның бер гимназиясендә булган. Укучылардан: «Александр Матросовны беләсезме?» – дип сораган. Әлбәттә инде, «Беләбез!» – дип, хор белән дигәндәй, әйтүләрен көткән. Тик балалар аптыраштта калып, иңнәрен генә сикерткәннәр. Алар – яңа идеология җимешләре.

Без – агач мылтыклар тотып, «сугыш-сугыш» уйнап үскән буын. Әмма күңелләрдә «агрессия» дигәннәренең «а» хәрефе дә юк иде. Мәктәптә, «Батырлык дәресләре»ндә хәрби хезмәт, сугыш каһарманнары, герой-пионерлар турында сөйләделәр. Без бала күңеле белән шуларга охшарга тырыштык, үзебезчә ватанны сакларга әзер идек. Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр боларның барын да әкрен-әкрен юкка чыгарды.

Шул ук Рөстәм Гомәров мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, хәтта югары уку йортларында да патриотик тәрбия бирүне беренче урынга куя. Баштарак мин моңа бик үк игътибар итмәгән идем, инде менә хәзер шуны уйлап утырам: һәркем алган гыйлемен, һөнәрен илгә хезмәткә җигәргә тиеш түгел микән? Әлбәттә, икенче яктан, ватан да үз баласын үги итәргә түгел, ә үз хезмәтенең җимешен татыр өчен менә дигән шартлар тудырырга тиеш. Ул чакта «акыллылар» чит илгә агылмас, читтә бәхет табарга теләүчеләр дә кимер иде. Туган илне яратырга өндәү ул – коры сүз генә.

Һәр җан иясенең иң әүвәл баш мие үлә. Мин башында мие булганнарны күз алдында тотам инде. Без яңа буында ил турында уйлау сәләтен бетердек кебек. Бәндә баласы кайда рәхәт – шунда яшәү турында гына уйлый. Бүген Украинада яңа идеология формалаша. АКШ, Европа илләре ярдәме белән халыкка бәйсез илдә җәннәттәй тормыш вәгъдә итәләр. Халыкта тарихи хәтер буталып бетте. Ә хәтерсез халыкның гомере озын була алмый.

Безне дошман күргән илләр Россияне сугыш кырында җиңәргә хыялланалар. Монысы бераз куркыту-әркетү өчен дип уйлыйм. Бу ызгышта икенче, тагын да куркыныч фронт бар, ул да булса – тарихи хәтер өчен сугыш. Кешене һәрвакыт идея, хәтер яшәткән. Русларда «Иван непомнящий» дигән гыйбарә яши. Шул исем-фамилияле кино актеры бар. Бу гыйбарә хәзер күчмә мәгънәдә дә йөри, ул патша Россиясендә үк кулланылышка кергән һәм хәтерсез, үз уе-фикере булмаган кешеләргә карата әйтелә. Тарихи мәгълүматлар буенча, сөргеннән качканнар, крепостной крестьяннар үзләренең үткәнен яшерү өчен: «Исемемне, нәселемне хәтерләмим», – дип әйтә торган булганнар, ди.

Бездә дә «Иван непомнящий»лар буыны барлыкка килмәсен иде дип әйтүем. Кем икәнебезне белеп, горурланып яшәргә өйрәник, күңелләр теләсә нинди коткыга бирелмәсен. Ә мондый тәрбия, әлбәттә, җәмгыять идеологиясенә бәйле.

РЕЦЕССИЯ КИЛӘ?

Без май ялларында утырганда, дөнья икътисадында тәшвишле һәм шомлы хәбәрләр саны артты. Вашингтонның сәяси лидерлары, дөньякүләм лидерлыкны саклыйбыз дип, тырма өстендә сикерү һәм бию не алга сөрә бара. Аңлашыла инде: тырмага бастыңмы, маңгайга шап итә: дөнья масштабында бәяләр күтәрелә, җитештерү кими башлый. Әчке тулай продуктны җитештерүне киметү рецессия дип атала. Җитештерүнең бер-ике айга гына кимүе кризис түгел, әлбәттә. Түбәнәю ике квартал рәттән дәвам итсә генә шомлы сигнал булырак кабул ителә. Рецессия эшсезлекнең артуын, чималга ихтыяҗ кимүен вәгъдә итә. Дөньякүләм рецессияне без соңгы тапкыр 2008–2010 елларда күзәткән идек. Ул чакта фонд базарлары җимерелде, бөлгән миллиардерлар поезд асларына ташланды, нефтьнең бәясе кризис алдыннан 147 долларга баскан иде, кискен түбән ташланып, 30 долларга һәм аннан да түбәнрәккә калды. Россия өчен соңгысы зур югалтуларга китерүе белән куркыныч иде, әмма глобаль икътисад лидерлары соңгы ат йөрешен ясадылар... Җөмләдәге соңгы дигән сүзгә игътибар итүегезне сорар идем. Дөнья сәясәтенең һәм икътисадының шахмат тактасында бүтән ат йөрешләре ясарлык җай калмады инде. Ат йөреше исә түбәннән гыйбарәт иде: үзәк банклар процент ставкаларын бик нык түбәнәйттеләр: кайсы нульгә якынлаштырды, кайсы нульдән дә түбәнәйтте. АКШта төп ставка – 0,5 процент тирәсе, Европа Үзәк банкында – 0, Швейцария банкында – минус 0,75 процент, Японииядә минус 0,1 процентка кадәр калдырылды. Төп ставканың түбәнәюе бизнеска һәм халыкка арзанлы кредитлар вәгъдә итә иде. Әйтик, Даниянең иң зур банкларыннан берсе Jyske Bank ун еллык срок белән минус 0,5 процентлы ипотека кредиты өләшә башлады. Күз алдыгызга китерегез: әҗәткә акча алсаң, арттырып түләмисең, ә кире кайтарып биргәндә, кимрәк акча сорыйлар. Сез шундый кредитка фатир сатып алыр идегезме? Алыр идегез, әлбәттә. Яртылаш коммунизм бит инде бу! Мондый шартларда төзелеш темплары үсә, арзанлы кредитка тиенгән бизнес та активлыкны нык арттыра. Ул чакта Көнбатыш дөньясы рецессиядән шулай итеп чыкты. Кризиска, саубуллашып, кул болгадылар. Миллиардерлар тагын акчаларын кая куярга белми башладылар. Беренче карашка бик уңышлы булып тоелса да, хәвефле ысул иде бу. Бүгенге дөньяда бара торган акылга сыймый торган хәлләр, вәхшәтнең артуы нәкъ менә шуның нәтиҗәсе инде.

Түбән процент белән акча өләшү өчен аны каяндыр алырга кирәк бит. Банкирлар акча эзләп азапланмадылар, билгеле. Станогы үз кулларында булгач, алар аны теләгән кадәр бастылар. Чынлыкта кредит итеп юк акча өләшенде. Күп булган саен товар очсызлана. Доллар, евро, лира, юаньнар барысы да очсызлана башлады, кыйммәтләрен югалттылар. Зур инфляция куркынычы туды. Инфляциядән качуның бер ысулы бар иде әле ләкин. Акчаны фонд базарына тыгу, ягъни кыйммәтле кәгазьләр сатып алу. Бу очракта товар бәяләре түгел, облигацияләр һәм акцияләр бәясе арта. Нефть, газ, алтын кебек товарлар фьючерслар белән сатылу сәбәпле, аларның бәяләре дә үсә инде, әлбәттә. Биржаларда кәгазь нефть, кәгазь алтын белән сәүдә итәләр чөнки. Моңа охшаш ысул безнең банкларда да кулланыла: алтын хисапка акча сала аласың. Кулыңа алтын бирмәячәкләр, ә 1 грамм алтын, 5 грамм алтын дигән кәгазь генә тоттырачаклар. Кәгазьдә синең алтының бар, ә чынлыкта юк. Бу ысул белән юк алтынны да күпме теләсәң, шуның кадәр сатып була. Беренче карашка бер дә зыянсыз булып тоелган бу уен зур дәһшәт вәгъдә итә. Бердән, кәгазь чималларга иярептчын нефть һәм газның да бәясе үсә, бу исә ахыр чиктә барлык товарларның да кыйммәтләнүенә китерә. Инфляция мәйданга чыга һәм гиперинфляциягә әйләнү куркынычы арта. Инфляциядән акчаны саклау өчен банкирлар һәм салым җыючылар телендә физик затлар дип аталган гади кешеләр дә биржа уенына кушылалар: акцияләр сатып ала башлыйлар. Бу фонд базарын яңа югарылыкка күтәрә: куыклар кабара. Ул гына җитмәсә, биткоин дигән ялган валютаны мәйданга чыгаралар. Биткоин сатып алдыңмы, байыйсың дигән пропаганда бар көченә эшли башлый. Чынлап та кайчандыр ун мең, егерме мең доллар торган цифрлы валютаның бәясе алтмыш мең долларга кадәр җитә. Ун меңгә алган кеше кыска гына вакыт эчендә алты тапкыр байый. Кыйммәтле кәгазьләр һәм цифрлы валютлар спекуляциясе реаль икътисадтагы акчаны суыра да аннан арттырып кайтарып бирергә тиеш була. Тик ничек кайтарасың, ничек арттырасың, халык акчасын юк әйберләргә тыкты. Нефть юк, кәгазе генә бар, «Фейсбук»ның берниндн матди кыйммәте дә юк диярлек, ә доллардагы бәясе кайбер державаларның байлыгыннан зуррак. Башка интернет компанияләр белән дә шул ук хәл. Билгеле бер күләмгә җиткәч, фонд биржаларында мәтәлчек башланмый кала алмый. Акционерларга ул кадәр акчаны кайтарып бирсәң, кибеткә ипи алырга долларларны капчыкка тутырып алып килергә кирәк булачак. Фонд биржасындагы түнтәрелеш санаулы көннәр һәм сәгатьләр эчендә йөзләгән миллиард һәм хәтта триллион долларны көлгә әйләндерә. Соңгы көннәрдә АКШта һәм башка илләрдә дә бик көчле базар түнтәрелеше башланды. Кайбер компанияләрнең бәясе ике урынлы сан белән очсызлана. Биткоин бәясе фонд базары белән бергә шиңә. Ул хәзер алтмыш мең доллар түгел, ә 34–35 мең генә йөри инде. Күз алдыгызга китерегез: югары ноктасында биткоин алган булсагыз, хәзер күпме югалтыр идегез?

Югарыда мин сөйләгәннәр иң куркынычы түгел әле. Аерым кешеләрнең фаҗигасе генә. Ул югалтуларда алар үзләре гаепле һәм әрнүләрен үз эчләренә йотарга мәҗбүрләр. Күпләп акча басу һәм арзанлы кредит өләшү реаль икътисадта да бәяләр күтәрелүгә китерми калмый. Башта инфляция сизелер-сизелмәс кенә була, аннан соң авырттыра торганга әйләнә. Базарга чыгып карагыз бүгенге бәяләр белән өч ай элекке бәяләрне. Бер бездә генә түгел, бөтен дөньяда хәл шундый. Газета хәбәрчесе Төркиядән менә мондый хәбәр алды: «Әле генә кибеттән 15 йомырка, 600 грамм сыр, балалар өчен 6 сок... сатып алдым, – дип яза хәбәрчем (тулы исемлекне кыскарттым. – **Р.Ф.**). – Барысы өчен 150 лира түләдем. Әле көз көне генә болар өчен, күп булса, 50 лира кирәк иде...» Башка илләрдәге бәяләрне китереп тормыйк. Шокның масштабын күз алдына китерү өчен монысы да җитә.

Бәяләрнең күтәрелешен халыкка аңлатырга кирәк була башлый. Җитәкчелек, без алып барган сәясәт шуңа китерде, дип әйтә алмый. Халык урамнарга чыгачак һәм лидерларны чәйнәк. 2020 елның февралендә лидерларны коронавирус пандемиясе башланып «коткарды». Юк, без, «Ковид-19» – ясалма вирус, дип расларга җыенмыйбыз. Кулыбызда ышандырырлык дәлилләр юк чөнки. Әмма локдауннар кертеп, килеп туган вазгыять өчен җаваплылыкны вирус өстенә аударырга җай чыкты. Без «Ватаным Татарстан»да шуңа күрә «пандемия кризисы түгел, кризис пандемиясе бу» дип язып чыктык. Әмма ковидчиклаучылар «козел отпущения» ролен бик кыска вакытка гына үтәделәр. Европада да, Америкада да массалар протест белән урамнарны тутыргач, уен картасын үзгәртергә туры килде: Россияне Донбасс тозагына тартып керттеләр. Гаеплене украин конфликты тирәсеннән эзләү модага керде. Аргентина Президенты Альберто Фернандс әле яңа гына: «Дөньяның бөтен илләре, аеруча Латин Америкасы һәм Африка Украинадагы конфликт нәтиҗәсендә газап чигә», – дип белдерде. Байден инде ничәнче тапкырдыр: «Илдә ягулыкка һәм азык-төлеккә бәяләр Путинның Украинадагы махсус операциясе нәтиҗәсендә үсә», – дигән игъланын ясады. Эшнең кая таба баруын сизәсезме? Беренче кварталда Америкада җитештерү 1,4 процентка кимеде. Кимү тагын бер квартал дәвам итсә, бу рецессия дип аталачак. Кытайда инде рецессия бара. Хәзер бәяләр күтәрелүен генә түгел, масакүләм эшсезлекне дә халыкка аңлатырга туры киләчәк. Кытай әлегә, 160 миллион халыкны гадәттән тыш карыс чикләүләр кысасында тотып, игътибарны читкә юнәлтә. Һаман да коронавирусны эксплуатацияли. Вазгыять контрольдән чыкса, Тайваньга һөҗүм итүне икенче уен картасы буларак саклый. Көнбатышның үз планнары бар. Кызганыч, ул планнар Россия белән бәйле. Кризис тирәнәйгән саен ил лидерлары үзләрен акылдан язган кебек тотачаклар, акка кара белән тегелгән сылтауларны сәбәп итеп, зуррак канкоеш оештырырга тырышачаклар. Башланып килүче рецессия менә шуның белән дәһшәтле дә инде. «Өч көн эчендә АКШта зәңгәр фишкалар (югары технологияле компанияләр акцияләре) капитализациясе 1 триллион долларга кимеде», – дигән рәсми хәбәрне шуңа күрә газета хәбәрчесе шомланып укый. Вазгыятьне тагын бер нәрсә кискенләштерә. «Йорт хайваннарын эзләү» дигән фильмда: «Күп кенә кешеләр психиатрик хастаханәләрдә булырга тиеш түгелләр, әмма алар шунда. Шул вакытта психиатрик клиникада булырга тиешле күпләр анда түгел», – дигән цитата бар икән. Соңгылары иректә генә түгел, ә финанс һәм сәяси хакимиятләрне дә җитәклиләр. Менә шунысы куркыныч та инде аның.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

БАСУ КАПКАСЫНДА – ЙОЗАК

Районның «Күтәмә» агрофирмасының чәчүлек җирләрен, үзләренә әйтминитми генә, башка кешеләргә арендага биргәннәр. Әлеге хуҗалыкны 17 ел җитәкләгән Фәнүзә Гобәйдуллина безгә: «Җирләребезне тартып алалар. Моңа кадәр эшләп килгән кырларыбыздан куып чыгардылар», – дип шалтыратты. Әлеге хәлнең сәбәпләрен ачыклар өчен, Чирмешән районына кузгалдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бүген – синеке, иртәгә – минеке

«Күтәмә» агрофирмасы чагыштырмача зур түгел. Узган ел ахырына кадәр хуҗалыкның 3200 гектар җире булган. Бүгенгә 120 баш мөгезле эре терлеге бар, шуның 30ы – савым сыеры. Болардан тыш, атлар тоталар. Дөрес, элгәрәк күпләп дуңгыз да асраганнар. Тик соңгы елларда илдә Африка чумасы таралганлыктан, аларны асраучы хуҗалыкларга контроль дә, игътибар да көчәйде. Шул сәбәпле, «Күтәмә» хуҗалыгы да дуңгызларын бетерергә мәҗбүр булган.

Агрофирманың 3200 гектар җире «Татнефтепром» җәмгыятенеке булып санала. Тик, агрофирма директоры Фәнүзә Гобәйдуллина әйтүенчә, оешмадан әллә ни зур ярдәм булмаган.

– 2009 елдан бирле агрофирма мөстәкыйль балансга, хуҗалыкны бары тик үз көчебез белән генә алып барабыз, – диде җитәкче ханым. – Техникаларны яңарттык, яхшы уңыш алып эшләдек. Гектарына 30–40 центнер уңыш җыеп килдек. (Чирмешән районы өчен бу яхшы күрсәткечләрдән санала. – **Авт.**) Корылык елларында да сынатмадык. Кешедән акча сорамадык, кредитка батмадык, бүген беркемгә дә бурычым юк. Салымнарны, хезмәт хакларын, пай җире өчен акчаны вакытында түләп бардык. Бүген-иртәгә чәчүебез бетәргә тиеш иде. Шушы кадәр җиргә җитәрлек орлык әзерләгән идек. Яңа чәчкеч алдык. Терлек азыгыбыз да бар. Райондагы дүрт ашлык киптергечнең икесе – минем хуҗалыкта. Хуҗалык гел алдынгылар рәтендә булды.

Чыннан да, Фәнүзә ханымның йорт диварында район башлыгы, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры имзалаган Мактау грамоталары шактый. Машина-трактор паркына да кереп чыктык. Ташландык, кызганыч хуҗалыкларны да күргән бар. «Күтәмә» агрофирмасын бер дә алай дип әйтеп булмый. Техникалары җитәрлек, амбарда ашлыклары, симәнәләре күп. Кыскасы, Фәнүзә Гобәйдуллинаны районда гына түгел, республикада да мактаулы, булдыклы җитәкче буларак беләләр. Хуҗалыкның алга таба да планнары зурдан булган югыйсә. Грант отып, тармакны тагын да зурайту турында уйлаганнар.

Әлегә кадәр шулай булган. Тик узган ел ахырында пай җирләрен башка инвесторга арендага биргәннәр. Быел язын хөкүмәт җирләрен дә тартып алганнар. Ни гаҗәп, күпьеллык үлән чәчкән кырлар да, узган көз эшкәрткәннәре дә башка кешеләр кулына күчкән.

– Җирләрне бездән 4–5 ел инде алырга тырышалар. Узган ел, мин авырган вакытта, октябрь аенда пайчылар җыелышы җыеп, җирләрнең бер өлешен алдылар. Минем белән киңәшләшүче кеше булмады. Югыйсә пайчылар белән килешүләр 15 декабрьгә кадәр төзелгән иде, – ди Фәнүзә Гобәйдуллина.

Аның сүзләренчә, агрофирма биләмәсендә 208 пай җире бар. Тик авыл халкы әйтүенчә, җыелышта 20–30 тирәсе генә кеше катнашкан.

– Без берни белми калдык. Әйтүче, җыелышка чакыручы булмады, – диде безгә пайчы Клава Васясина. – Җыелышта халык күп булган дип язганнар. Укытучылар, балалар бакчасында эшләүчеләр килгән булырга тиеш. Алар гына аз була бит. Кыскасы, барысын да бездән башка хәл иткәннәр. Моңа кадәр пай җирләре өчен акча алу белән берниндиди дә проблема булмады. Һәрвакыт вакытында алып бардык. Барысыннан да канәгать идек.

Җыелышта катнашкан пайчы Владимир Поляков та авылдашының сүзләрен раслады. Аның әйтүенчә, җыелышка 20–30лап тирәсе кеше килгән. Ягъни кеше саны тиешле таләпләргә җавап бирми һәм кворум җыелмаган булып чыга түгелме? Тик җыелышта булган Күтәмә авыл җирлеге башлыгы Самат Хәйруллин сүзләренчә, беркетмәдә 121 кеше күрсәтелгән.

– Без ничек бар, шулай эшләдек. Берниндиди дә ялган юк, – диде ул. – Зал шыгрым тулы иде. Сәркатип кыз барысын да санап язды. Фәнүзә пайчыларга 750 сум акча түләп килде. Бу мәсьәләдә аңа бер сүз дә юк. Узган ел, корылык булу сәбәпле, саламы булмады. Шуңа күрә аңа карата халыкның канәгатьсезлеге бар иде. Җыелышта барысы да бертавыштан җирләрен башка инвесторга бирергә ризалык белдерделәр. Хөкүмәт җирләренә килгәндә, агрофирма 800 гектар җиренә берни дә утыртмады, кирәксенмәде. Быел килешү вакыты чыкты.

Фәнүзә ханымның улы һәм хуҗалыкта төп ярдәмчесе Илнур Гобәйдуллин сүзләренә караганда, яңа инвестор пайчыларны яхшы бәя белән кызыксындырган.

– Җирләргә акчаны арттырабыз, печән, салам бирәбез, дип ышандырганнар. Тик, белүебезчә, аларның җирләренә көнбагыш чәчәргә планлаштыралар. Димәк, халык печән-саламсыз калачак дигән сүз. Хәзер пайчылар канәгатьсезлек белдерә, – диде ул.

Ярар, пайчылар үз җирләрен теләгән кешеләргә бирсен дә ди, тик хөкүмәт җирләрен алулары бөтенләй өнсез калдырган Фәнүзә Гобәйдуллинаны.

– Моңа кадәр безнə: «Ул җирләрне алмыйбыз», – дип ышандырып килделәр. Аларны көздән эшкәрттек, сукаладык. 20 апрельдә чәчүлек җирләренә төшеп, техника керткәч, полиция, тикшерүчеләр чакыртып, безне куып чыгардылар. Шуннан соң, тәгаенләр өчен, районның Җир мөнәсәбәтләре палатасына мөрәҗәгать иттек. Ул кәгазь буенча барысын да аңлатып, күрсәтеп бирде. Без бөтенләй телсез калдык. Мин бит яңа чәчкечне көзен сатып алдым. Ни өчен алар (район җитәкчелеге) ул вакытта ук әйтмәгән? Алар кемнең нинди мөмкинлекләре барлыгын белми, хуҗалык эшчәнлеге белән кызыксынмыймыни? – ди агрофирма җитәкчесе.

Сәбәп нидә?

Шулай итеп, бүгенгә «Күтәмә» җәмгыятенә 210 гектар җир калдырганнар. Дуңгызчылыкны бетергәч сатып алынган мөгезле эре терлек Илнур Гобәйдуллин исемендәге крестьян-фермер хуҗалыгына теркәлгән. Аның 350 гектарын өстәгәч, 600 гектарга якын җир мәйданы килеп чыга.

– Хәлләр болай булгач, малларны бетермичә хәлебез юк. Амбар тулы ашлыкларыбызны да сатарга туры киләчәк. Башкача булмый, – дип көрсенә әниле-уллы Гобәйдуллиннар.

Хуҗалыкның күпчелек җирләрен менә шулай астыртын рәвештә генә башкаларга алып бирүгә нәрсә сәбәпче булган соң? Әлеге сорауны без районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Мирзаһит Гатинга бирдек. Кызганыч, ул безгә барысын да аңлатып, озаклап сөйләшүне кирәксенмәде. Аның әйтүенчә, агрофирма башлыгы, пай җирләрен эшкәртә алмау сәбәпле, үзе биргән.

– Фәнүзә күпчелек җирләрен берничә ел эшкәртмәде, чүп бастырып яткырды. Белгечләре калмады, халыкка саламын бирә алмады, пай җирләре өчен түләмәде. Узган ел 506 гектарына башка егетләр ашлык чәчте. Инвесторлар киткәч, минем җирләрне алыгыз, дип берничә ел үзе йөрде бит ул. Хәзер башкача уйлый, сөйли башлаганмыни? – диде идарә башлыгы.

Пайчылар башка инвестор белән аренда килешүе төзеде дисә дә, башта аның исемен әйтергә теләмәде. Мирзаһит Гатин сүзләре буенча, хөкүмәт җирләре исә агрофирманың үзендә калган. Тик соңрак ул аларның үзенең улы Дамир Гатинга күчерелүен белдерде.

Чыннан да, «ВТ» хәбәрчесенә билгеле булганча, хөкүмәт җирләре (400 гектар) Дамир Гатин исеменә теркәлгән. Пай һәм башка җирләр – шәхси эшмәкәр исемендә. Язманы әзерләгәндә, Кармыш авылында яшәүче фермер Дамир Гатин безгә үзе мөрәҗәгать итте.

– Безнең якларга килеп киткәнсез икән. Минем дә әйтер сүзем бар иде, – диде ул. – Мин бу җирләрдә беренче ел гына чәчмим. Дүртенче сезон анда эшлим. Узган елларда Фәнүзә апа: «Энем, юл буйларында чүп үлән үсеп утыра. Шул урыннарга чәч», – дигәч, эшкәртеп, ашлык чәчтем. Саламын халыкка тараттым. Тик моңа кадәр ул җирләр рәсмиләштерелмәгән иде, быел документлаштырдык. Аерма шунда гына. Моннан кала минем әле Елхово авылында 680 гектарга якын җирем бар.

Аның сүзләренчә, фермерның Кармыш авылында 268 баш мөгезле эре терлеге, 13 баш аты бар. Тик әлеге райондагы башка фермерлар, халык аның ул кадәрле малы булмавын әйтте.

Җир тәме

– Мин бу кадәрле үк булыр дип уйламаган идем, – диде Фәнүзә ханым, идарә башлыгының сүзләрен шәрехләп. – Минем бервакытта да җирдән баш тартканым булмады. Киресенчә, маллар санын арттыру уе бар иде. Бөтен мәйданнарда иген игелде, пайчыларга да 2009 елдан бирле үзем түләп киләм. Дамирның безнең җирләрдә ашлык чәчкәне булмады. Ничек шулай алдалап була икән ул? Узган көз уракны беренчеләрдән булып тәмамладык та сентябрьдә үк сөрүгә кереште. Моңа кадәр дә гел шулай алдынгылар рәтендә идем.

Фәнүзә ханым кул кушырып утыра торганнардан түгел анысы. Берничә тапкыр район башлыгы Фердинант Дәүләтшинга да мөрәҗәгать иткән, хатлар юллаган. Тик, кызганыч, аннан яклау тапмаган. Район башлыгыннан: «150 баш мал өчен 450 гектар сөрүлек җире җитә», – дигән җавап хаты гына килеп ирешкән. Апрель ахырында прокуратурага да мөрәҗәгать иткән, тик әлегә җавап кына ала алмаган.

Кырларда эшнең иң кызган чоры. Без барган көнне яңгыр яву сәбәпле, чәчү, эшкәртү эшләре тукталып торган иде.

– Менә монысын көздән эшкәрткән идек. Әнә тегендә дә безнең җирләр иде... Әлегә эшләгән кеше күренми, – дип, әле кайчан гына агрофирманыкы булган җирләргә моңсу караш ташлады Фәнүзә Гобәйдуллина. – Шушында ашлык үстерер өчен күпме көч түгелде, күпме йокысыз төннәр, мәшәкатьле көннәр үткәрдек. Җирнең тәмен, анда эшләүнең рәхәтен сөйләп кенә аңлатып бетереп булмый шул.

САНАГАННЫ ЯРАТА

АКЧАНЫ САКЛАРГАМЫ, ТОТАРГАМЫ, АЛМАШТЫРЫРГАМЫ?

Акчаның кирәк булмаган чагы бармы икән аның? Киеренке чорда аны аеруча сак кулланырга кирәк. Булганын ничек тотарга? Халык арасында популярлаша барган инвестиция белән шөгыльләнә башларгамы? Кризис – чыннан да, мөмкинлекләр вакытымы? Икътисади кыенлык чорында ничек коткыга бирелмәскә? Гомумән, нишләргә?

Югалтмыйча баю мөмкинме?

Акча мәсьәләсенә бәйле сорауларны финанс белгече Ләйсән ХАЛИКОВАга бирдек.

1. Билгеле бер күләмдә акча җыеп, аны нишләтергә белмичә, шул ук вакытта инфляция «ашар» дип курыккан гади кешегә хәзер нишләргә?
Җыелган акча ул кадәр зур күләмдә түгел икән, инвестициягә тотынганчы йөз кат уйларга киңәш итәр идем. Инвестиция – акчаны күпмедер вакытка «туңдыру» дигән сүз дә бит ул. Әлбәттә, бу акчагызны ала алмыйсыз дигәнне аңлатмый. Әмма акчагызны кертәсез икән, кыска вакыт эчендә генә сез теләгән нәтиҗәсен бирмәскә мөмкин ул.

Нишләргә? Гел әйтә киләм: кешенең билгеле бер күләмдә тупланган акчасы бар икән, иң элек, ул үзенең «финанс мендәре»н булдырсын иде.

Коронавирус пандемиясе чорын гына алыйк. Барысын да үзебездә тойдык, күрдек. Күпме кеше эшсез-акчасыз калды. «Финанс мендәре» булмаган кешегә кыенга туры килде. Дөньяда нинди генә катлаулы вазгыять булуга карамастан, «финанс мендәре» әзер торырга тиеш. Инфляция дип сөйлибез икән, «финанс мендәре»нә тотылып калачак сумма да күбрәк булса, яхшырак.

«Финанс мендәре»н булдырган кешеләргә еш кына диверсификация ясарга киңәш итәбез. Ягъни акчаның бер өлешен сумнарда, бер өлешен башка валютада тотарга мөмкин. Анысын һәр кеше үз хәл итә.

Нинди дер җыелган акча бар икән, минемчә, аны гыйлем алу, белем арттыруга тоту яхшырак. Кемдер, мәсәлән, өстәмә һөнәр алырга мөмкин. Яисә бизнеска кертем ясарга. Хәзерге вакытта импортны алмаштыру процессы бара. Чит илдән күп кенә товарлар керми башлады. Хәзер безнең өчен мөмкинлекләр вакыты. Нинди дер сәләтегез, шөгылегез бар икән, файдаланып калырга кирәк. Әйтик, тегә беләсез, ди. Бизнес җаелдереп җибәрергә, электрон сәүдә мәйданчыкларына (маркетплейс) чыгарга мөмкинлек бар. Минемчә, хәзер үзеннең эшеңне җаелдерү өчен кулай вакыт. Социаль челтәрләрнең кайсылары чикләнсә дә, булганнарында үз товарларыңны күрсәтү мөмкин бит.

Кешене милек мәсьәләләренә кагылышлы сораулар да борчымый түгелдер. Әгәр дә милек сатып алу белән кызыксынасыз икән, акчаны диверсификация рәвешендә милеккә кертергә дә мөмкин. Әлбәттә, сумма зур булган очракта, милек бәясе ничек артканын барыбыз да белә.

2. Ә нәрсә эшләмәскә?
Ашыгып, акчаны теләсә кая кертмәскә. Хәзерге вазгыятьтә «акыл сатучылар» да, мәгълүмат таратучылар да күп. Акция дип, монысын алыгыз, тегесен дип киңәш итүчеләр байтак. Ашыгыч рәвештә, коткыга бирелеп, акчаны шуларга тотмаска киңәш итәр идем. Һәр адымны уйлап эш итәргә кирәк. Фонд базарына керергә җыенасыз икән, «бу миңа кирәкме?» дип йөз кат уйлау хәерлерәк. Керер алдыннан, үзегезнең финанс мөмкинлекләрне барлыйсы булыр. Беренчедән, сезнең әҗәтләрегез булырга тиеш түгел. Аннан, «финанс мендәре», тормышыгыз иминиятләштерелгән булса хәерле.

3. Банк продуктларыннан (кертем, кредит һ.б.) ничек файдаланырга?
Кертемнәрне озак вакытка ачарга киңәш итмәс идем. Гади генә итеп әйтсәк, булган акчаны озакка банкка бирмәскә. Иң кулай вакыт – 6 ай. Искәрмә дә бар: банкның нинди дер проблемалары чыга яисә банкрот булып танылса икән, 1 млн 400 меңнән арткан сумма сезгә кире кайтмаячак. Кертем суммасын шуннан да арттырмаска киңәш итәм. Иминиятләштерелә торган сумма – 1 млн 400 мең.

Кредит мәсьәләсенә килгәндә, элегрәк кредит алып калган кешеләргә хәзер азмы-күпме җиңелрәк. Хәзер бит процентлар зуррак. Яңа кредит алырга теләүчеләргә исә ашыкмаска киңәш итәм. Бик тә кирәк икән, ташламалы шартларны барларга кирәк. Тәкъдимнәр булып тора. Баштан шуларны карарга, кызыксынырга кирәк. Кредит алу – ашыгып эшли торган эш түгел.

4. Инвестицияне нәрсәдән башларга?
Инвестиция белән кызыксына башлагансыз икән, иң элек диверсификация ясарга кирәк. Ягъни барлык йомыркаларны да бер кәрҗингә тутырырга кирәкми. Әйтик, бер төрле акциягә генә карарга түгел. Төрле оешма-компанияләрне күзәтергә киңәш итәр идем. Төп мантыйк нәрсәдә? Бөтен булган акчаны бер урынга тутырырга кирәкми.

Инвестиция белән кызыксынып, акча эшләргә җыенасыз икән, шуны аңлагыз: бу – озак вакытка исәпләнгән адым. Ягъни моннан-тегеннән алдым-саттым дип, акча эшләп булмаячак. Базар тотрыклы түгел. Алга таба ни буласын белеп булмый. Берничә сәгать эчендә генә дә үзгәрешләр булып тора. Шуңа күрә инвестиция белән эшли башласагыз, акция алырга һәм ул хакта берникадәр вакытка онытып торырга кирәк. Тәүлек буе сатып алган акциягезне күзәтеп, аңа текәлеп тору хәерле түгел. Сез бит трейдер (биржа сәүдәсендә катнашучы. – **Авт.**) түгел, моның белән генә шөгыльләнмисез. Әллә нигә бер үсүен-төшүен күзәтеп торырга мөмкин. Әмма инвестицияләү сезнең борчылуның сәбәпчесенә әйләнергә тиеш түгел.

Үзегез генә моны ерып чыга алмам дип куркасыз, ләкин инвестиция белән мавыгып карарга телисез икән, финанс киңәшчесенә мөрәҗәгать итәргә була. Шулай да, җаваплылык үз өстегездә кала.

5. Инвестиция белән әле яңа гына шөгыльләнә башлаганнарга һәм тәҗрибәле инвесторларга хәзерге вакытта икътисадның кайсы өлкәләренә игътибар итәргә?
Аналитикларга ышансаң, металлургия, чимал җитештерү, энергетика секторына игътибар бирергә кирәк. Шулай ук мәгълүмати технологияләр (IT) тармагы популярлаша башлады. Шушы өлкәләрне карарга була. Алдан әйтүемчә, бер генә тармакка берегергә кирәкми, төрле өлкәләргә кереп, диверсификация ясарга тәкъдим итәм.

6. Кризис чорында ничек итеп коткыга бирелмәскә?
Әгәр дә сезнең финанс планыгыз бар, барлык бюджетыгыз алдагы 3–5 елга планлаштырылган, «финанс мендәре», тотрыклы эшегез булса, әҗәтләрегез калмаса, бу вакытта бернинди дә куркыныч янамый. Шуңа коткыга урын да юк. Хәзерге чорда акча белән дөрес эш итәргә өйрәнергә кирәк. Теләсә нәрсәгә акча туздыра торган чак түгел.

Уйнап баю

Ничек кенә сәер яңгырамасын, иренмәсәң, уйнап та акчаны янда калдырырга була икән. Юк, сүз уен автоматлары, казино һәм башка комарлы ысуллар турында түгел. Күз карашы белән генә акчаны үрчетеп булмый, билгеле. Монда гап-гади психология ярдәмгә килә.

Билгеле бер суммадан азмы-күпме акчаны тотып калырга өйрәнергә кирәк. Моның өчен уйный-уйный теләгән сумманы тупларга мөмкинлек бирә торган алымнар бар.

«Конвертлар» кагыйдәсе. Табышны процентларга бүлеп карыйбыз. Айлык фәлән сумма 100 процент булачак. Шуннан бу акчаны 6 конвертка бүлегез. Түбәндәге тәртип буенча: 10 процент – «финанс мендәре», 55 процент – мәҗбүри чыгымнар (коммуналь хезмәтләр өчен түләү, бурыч, ризык сатып алу һ.б.), тагын 10ар процент – белем алу һәм шәхси кирәк-яраклар өчен (запас). 5 процентын бүләкләр, хәйрия, ярдәмләшүгә тотарга була. Монысы өчен акчаны азрак та калдырырга, шул хисапка кайсыдыр конвертны «тазарак» итү мөмкин. Тагын 10 процент маяны күңел ачу өчен тоту яхшы. Кайсыдыр конвертта акча калган очракта, аны «финанс мендәре» саналган конвертка күчерергә онытмагыз.

«52 атна» кагыйдәсе. Акча җыю өчен тартма алыгыз. Беренче атнада билгеле бер күләмдә акча салыгыз. Шуннан атна саен бу сумманы шул сумма күләмендә арттырып торыгыз. Әйтик, беренче атнада – 50 сум, ди. Икенче атнада – 100, өченчесендә 150 сум салырга тиеш буласыз. Атна һәм ай азагында җыелган сумма күңелегезне күтәрәчәк.

«Коллекционер» кагыйдәсе. Бу – бик гади уен. Балачакны да искә төшермәгәе әле ул. Әти-әни, әби-бабайлар «туңдырма алып ашарсың» дип, азмы-күпме кесә акчасы биргәли иде бит әле? Менә монда да шул кагыйдә эшли. Кулыгызга килеп эләккән билгеле бер суммадагы кәгазь акчаны туплап барыгыз. Әйтик, 200лекләрне. Сирәк очрый торган акча булса кызыграк.

«Баш тарту» уены. Уйлап карагыз әле: көн саен сез даими рәвештә нәрсә сатып аласыз? Мәсәлән, каһвә, ди. Аның бәясе 150 сумнан башлап артыграк та булырга мөмкин. Әйдәгез, көнегезне каһвәдән баш тартам дип башлап карагыз. Ә аңа тотыласы акчаны мая итеп җыегыз. Бу – ихтыяр көченә дә сынап карарга бер мөмкинлек бит.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«Татар-информ»

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге сораштыруы нәтиҗәсенә караганда, Россиядә яшәүчеләрнең 46 проценты булган акчаны милек сатып алуга тоту яклы. Моны алар иң ышанычлы ысул дип саный. 29 проценты маясын банкта саклауны хуп күрә. 14 проценты акчасын алтынга, кыйммәтле эшләнмәләр сатып алырга тотар иде икән. Сораштыруда катнашучыларның 10 проценты, акчаны чит ил валютасында сакларга кирәк, дигән. 7 проценты – акция сатып алу, 5 проценты Пенсия фондына илтеп бирү яклы.

20 май сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә бүлек мөдире **Фәния Әхмәтҗанова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Ник иртә бетерәләр?

– Йортларда җылылыкны ник иртә бетерәләр икән ул? Минә инде кайчаннан бирле туңып утырабыз. Күршеләрем дә зарлана. Апрель дә, май да җәй ае түгел бит. Советлар Союзы заманында 9 майга кадәр йортларда җылылыкны бетермиләр иде. Коронавирус белән авырган кешеләр дә гел туңудан зарлана. Өйдәге җылылыкны вакытыннан алда бетереп куйгач, аларга икеләтә авыр бит. Нишләп хәзер кеше турында уйламыйлар икән?

Дания ЯРУЛЛИНА. Казанның Дәрвишләр бистәсе

Казан мэриясенең матбугат хезмәте:
– Һава температурасы билгеле бер күрсәткечкә җиткәч, күпфатирлы йортларга җылылык бирү туктатыла. Моның өчен биш көн дәвамында урамда ким дигәндә 8 градус җылы сакланырга тиеш. Кызганыч, йортларда җылылык өзелгәч, техник яктан аны яңадан кушу мөмкин түгел. Бу норматив федераль дәрәҗәдә билгеләнгән. Ул эш Россия Хөкүмәтенең «Милекчеләргә һәм күпфатирлы йортлардан һәм торак йортлардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында»гы карары, «Госстрой»ның «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларын раслау турында»гы карары нигезендә башкарыла.

Чит илгә чыга аламмы?

Моңарчы алиментны вакытында түләп барган идем. Соңгы айларда эшсез калдым. Үземнең күпме бурычым барлыкны каян белеп була? Ничә сум бурыч булса, чит илгә чыгармыйлар?

Наил КАШАПОВ. Чаллы

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстанның баш суд приставы урынбасары Елена Варфоломеева:
– Бурычлар хакында Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе сайтының төп битендә һәм Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең мобиль кушымтасы аша белергә була. Бурычы бармы-юкмы икәнлеген белү өчен, кешегә сайтка кергәч, фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм туган көнен язарга кирәк. Әҗәте булган очракта аның хакында бөтен мәгълүмат күрсәтеләчәк. «Банк данных исполнительных производств» хезмәтеннән файдаланып, бурычны түләү өчен квитанцияне чыгартып алырга һәм теләсә нинди уңайлы ысул белән, шул исәптән сайт аша да түләргә мөмкин.

Хәзерге вакытта Татарстанда яшәүче 108 мең кешегә читкә чыгу чикләнгән. Бурыч 30 мең сумнан артык булмаска тиеш. Аэропортта күңелсез хәл килеп чыкмасын өчен, әҗәтегезне алдан ук тикшереп һәм түләп куегыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укучы сүзе

ЧЕРНОБЫЛЬНЕҢ КАРА КӨННӘРЕ

Ул коткаручылар арасында минем әтием дә бар. Алардан сорап та тормадылар. Кемнең ике баласы бар – военкомат хезмәткәрләре аларны сугышка алып киткәндәй алып киттеләр. Станциянең үзендә хезмәт итеп, тиен хезмәт хакына эшләп, кире исән-сау әйләнеп кайттылар. Аңа тиешле акчаны без үскәч кенә, суд аша рәсмиләштердек. Хәзерге вакытта аларны искә алучы да юк. Ә бит алар сугыш ветераннары белән бер рәттә торырга тиешләр. Сугышка бару белән бер булды ул аларга. Әтием мохтаҗ кеше түгел, Аллаһка шөкер. Әмма бу көнне ел саен районның социаль яклау хезмәтеннән игътибар, рәхмәт сүзләре ишетмәмме дип көтеп тора. Ил башлыклары әзрәк әнә шуларга игътибар итсеннәр иде.

РӘМЗИЯ

***

ГӨЛНАЗ БАТТАЛОВА: «АЛЕКСКА ТАТАР ҖЫРЛАРЫ БИК ОШЫЙ»

Дөньядан артта калганбыз икән. Бу танылган җырчы турында ишеткән юк иде.

Наһирә ХАРИСОВА

***

Алар – танылмаганнар арасында танылган артистлар. Күбесе – Татарстанның атказанган артистлары да әле.

Дилбәр ДӘМИНОВА

***

РӨСТӘМ ЗАКИРОВНЫҢ УЛЫ АЙРАТ: «ҮЗЕҢ ТЫРЫШМАСАҢ, ФАМИЛИЯ ГЕНӘ БУЛЫШМЫЙ»

Әңгәмә эчкерсез һәм үз эченә алып керәп китә! «Афәрин якташым Рөстәм Закиров улына!» – диясе килә. Уңышлар юлдаш булсын!

Факия ШӘРӘФЕТДИНОВА

Фикер

Тел – милләтнең нигезе. Анда халыкның тарихы, рухи халәте, дөньяга карашы, тәҗрибәсе, кайгы-хәсрәтләре, теләк-өметләре, иске дөньясы чагыла. Татар баласы үз ана телендә белем һәм тиешле тәрбия алмаса, милләтебез юкка чыгарга да мөмкин. Үз милләтеннән булган, үз динен тоткан газиз парны табып, аны гомерлек яр итеп сайлап алып яшәү күпкә хәерлерәк. Татар яшьләре үзләрен мондый бәхеттән мәхрүм итмәсеннәр иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ. Казан

Машина чокырга төшсә, ни эшләргә?

– Яңгырлы көнне машинам юлдагы чокырга төшеп китте. Бер як тәгәрмәч белән бампер ватылды. Андый чакта да ЮХИДИ чакыртып, беркетмә төзетергә кирәк, диләр. Шуны аңлата алмассызмы икән?

РИЗВАН. Казан

Александр Ермаков, юрист:
– Машинаның юлдагы чокырга төшеп ватылуы закон нигезендә юл һәлакәте (ДТП) санала. Шуңа күрә аны да рәсми рәвештә теркәргә кирәк. Дөрес, ул җиңелчә юл һәлакәте санала, шуңа күрә ЮХИДИ инспекторлары аны, гадәттә, мөстәкыйль рәвештә генә теркәргә куша. Әмма болай эшләү бер дә отышлы түгел. Инспектор машинаның нәкъ менә юлларның начар булуы аркасында ватылганын теркәргә тиеш. Ул язып биргән белешмәдә машинаның маркасы, аның кайсы өлеше, ни дәрәҗәдә, кайда, кайчан зыян күргәне – барысы да төгәл күрсәтелергә тиеш. Моннан тыш машина төшкән чокырның озынлыгы, киңлеге, тирәнлеге күрсәтеп, акт та төзелергә тиеш. Бу урында чокыр барлыгы турында кисәткән юл билгеләренең юклыгын да күрсәтергә кирәк. Бу документ булмаса, юлчылардан матди зыян өчен акча таләп итеп булмаячак. Инспектор бу һәлакәттә сезнең бер гаебегез дә булмау турында беркетмә төзеп бирсә, яхшы булачак. Бу көнне төзелгән барлык документларның күчермәсен ясагыз.

Янгызда шаһитлар да булса, телефон номерларын алып, алардан вакыйга булган урын адресын, чокырга төшкән машинагызны, аның ватылган, яньчелгән, кителгән урыннарын, чокырны фотога төшерүләрен сорагыз.

Юлларның торышына кагылышлы ГОСТ таләпләре нигезендә, юл ятмасында җитешсезлекләр булырга мөмкин. Әмма аларның зурлыгы билгеле бер үлчәмнән артмаска тиеш. Әйтик, юллардагы чокырларның озынлыгы – 15 сантиметрдан, тирәнлеге – 5 сантиметр һәм мәйданы 600 квадрат сантиметрдан да зур булмаска тиеш. Әгәр машинага зыян салган чокырның зурлыгы шушы саннардан артып китсә, матди зыян өчен ярдәм сорарга мөмкин. Моның өчен бәйсез белгеч чакыртып, машинага салынган зыянны исәпләтергә туры киләчәк.

Аннары, сезнең машинагызга зыян салган юлның кайсы оешма карамагында икәнлеген ачыклап, җитәкчелектән, матди зыян өчен акча таләп итеп, дәгъва белдерергә кирәк. Хатка җавап бирүче булмаса, судка гариза язарга туры киләчәк.

Дөрес, ЮХИДИ инспекторлары бу очракта машина йөртүченең үзен дә гаепле итеп калдырырга мөмкин. Юл йөрү кагыйдәләренең 10.1 пункты нигезендә «тимер ат» иясе һава шартларына бәйле рәвешле тиешле тизлекне сайларга, куркыныч булган очракта, туктарга тиеш. Шуңа күрә әгәр машина йөртүче үзе гаепле булса, эшне зурга җибәрүдән мәгънә юк. Әмма авария юлдагы яшерен чокыр, кимчелекләр аркасында чыккан булса, ахыргача үз сүзеңдә торып, инспекторларга беркетмәне дөрес итеп төзетергә кирәк.

Кабер өстенә басарга ярыймы?

– Елларда авылга кайткач, зиратта чардуганнар буядык. Кабер аралары бик тар. Чардуганны эчке яктан, кабернең бер өлешенә басып буярга туры килде. Өйгә кайтканнан бирле шуңа эч пошып йөри. Чардуган буяганда кабер өстенә басарга ярыймы?

Гөлфия ШАКИРОВА. Арча

Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы:
– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кабер өстенә басуга караганда, тимер яки кызган әйбер өстенә басу, утыру хәерлерәк», – дигән. Шуңа күрә ничек кенә булса да кабер өстенә басмаска тырышырга кирәк. Әгәр чардуган буяганда кабер өстенә басарга туры килә икән, аны артык буямау кадерлерәк. Ягъни аның кабер өстенә бастырмый торган өлешләрен яхшылап буяп чыгарга да калган җирләрен, анда басмыйча, җиңелчә генә буярга кирәк. Кабер өстенә басмыйча буяп булмаса, чардуганны алмаштырырга кирәк. Бу бит исән кеше өстенә басып эш эшләү белән бер. Мәсәлән, синең якын кешең, авырып, диванда ята, сиңа аның янындагы диварны буярга кирәк, ди. Син бит инде бу эшне аның өстенә басып эшләмәячәксең. Монда да шул ук хәл.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

16 май | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
10.00, 23.30 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Информационный геноцид. Война на уничтожение против России» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Рыцари вечности». Гавриил Державин 12+
00.35 «Фолиант в столетнем переплете». Виды Казани, рисованные с натуры Э. Турнерелли 6+
00.50 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Ватандашлар» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ВАША ЧЕСТЬ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 «АнтиФейк» 16+
00.20 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.40 «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30, 18.40 Новости
06.05, 12.55, 15.40, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.20 Хоккей. Чемпионат мира. Чехия – Швеция. Трансляция из Финляндии 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30 Хоккей. Чемпионат мира. Дания – Швейцария. Трансляция из Финляндии 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Словакия – Канада. Прямая трансляция из Финляндии
18.45 «Громко». Прямой эфир
20.15 Хоккей. Чемпионат мира. Финляндия – США. Прямая трансляция из Финляндии
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Лацио». Прямая трансляция
00.25 Тотальный футбол 12+
00.55 Хоккей. Чемпионат мира. Латвия – Норвегия. Трансляция из Финляндии 0+
02.55 «Наши иностранцы» 12+
03.20 Новости 0+
03.25 «Оседлай свою мечту» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ВСПЫШКА» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
02.50 Их нравы 0+
03.15 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25, 03.20 «Порча» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «НАСЕДКА» 16+
19.00 «НИКОГДА НЕ БЫВАЕТ ПОЗДНО» 16+
22.40 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3» 16+
00.35 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
02.30 «Понять. Простить» 16+
03.45 «Знахарка» 16+
04.10 «Верну любимого» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «Война в Корее». Докудрама. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30 «Освобождение». Док. сериал 16+
10.00 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». Телесериал («Ленфильм», 1979). «Знакомство» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.20 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.35, 14.05 «Артиллерия Второй мировой войны». Док. сериал. «Бог войны» 16+
14.00 Военные новости. 16+
14.25 «СОБР». 1-я - 4-я серии 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Звёздный путь Николая Елизарова: как слесарь с «Уралмаша» стал президентом Тайваня». Премьера! 12+
23.15 «ПОД КАМЕННЫМ НЕБОМ» 12+
00.40 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
01.55 «ГДЕ 042?» 12+
03.10 «Из всех орудий». Док. фильм 16+
03.45 «СОБР». 1-я и 2-я серии 16+

17 май | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.50 «Чёрная курица, или Подземные жители». Спектакль Театра-студии «Театралика» по повести А.Погорельского (г. Саратов) 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Менделеев и его таблица 12+
00.50 «Рыцари вечности» 12+
01.05 «Фолиант в столетнем переплете». Редкое турецкое издание Всемирного атласа 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рөстәм Вәлиев турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ВАША ЧЕСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «АнтиФейк» 16+
00.25 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.40 «ВЕРСИЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.30 Новости
06.05, 12.55, 15.40, 22.40 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.20 Хоккей. Чемпионат мира. Финляндия – США. Трансляция из Финляндии 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30 Хоккей. Чемпионат мира. Франция – Германия. Трансляция из Финляндии 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Чехия – Австрия. Прямая трансляция из Финляндии
18.40 Гандбол. Чемпионат России «Олимпбет-Суперлига». Женщины. 1/2 финала. ЦСКА – «Звезда» (Звенигород). Прямая трансляция
20.15 Хоккей. Чемпионат мира. Швейцария – Казахстан. Прямая трансляция из Финляндии
23.30 Хоккей. Чемпионат мира. Италия – Дания. Трансляция из Финляндии 0+
01.35 Гандбол. Чемпионат России «Олимпбет-Суперлига». Женщины. 1/2 финала. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Лада» (Тольятти) 0+
02.55 «Правила игры» 12+
03.20 Новости 0+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. «Бока Хуниорс» (Аргентина) – «Коринтианс» (Бразилия). Прямая трансляция

НТВ

04.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ВСПЫШКА» (S) 16+
23.25 «ПЁС» (S) 16+
02.55 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.25 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Мальчик» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ВЕРНИ МОЮ ЖИЗНЬ» 16+
19.00 «НАША ДОКТОР» 16+
22.30 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3» 16+
00.20 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
02.10 «Понять. Простить» 16+
03.00 «Порча» 16+
03.25 «Знахарка» 16+
03.50 «Верну любимого» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «Пять ужинов» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СОБР» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30 «Освобождение» 16+
10.00 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «КРОВАВАЯ НАДПИСЬ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.45 «Спец. репортаж» 16+
13.40, 14.05 «Артиллерия Второй мировой войны». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
14.25 «СОБР». 5-я – 8-я серии 16+
22.00 «Между тем» 12+
22.25 «Улика из прошлого». «Крымские войны. Тайна прошлого и настоящего». Премьера! 16+
23.15 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «ЗНАКОМСТВО» 12+
00.25 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
02.05 «ПОД КАМЕННЫМ НЕБОМ» 12+
03.30 «Москва фронту». Док. сериал 16+
03.50 «СОБР» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 16–22 МАЙ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бик урынлы һәм оста итеп әйткән тәнкыйть сүзләрегез берәүләрне уйга салыр, икенчеләрнең ачуын чыгарыр. Эштәге киеренкелекнең берникадәр кимүе өй, ял һәм күңелгә ятышлы башка әйберләр турында уйлый башлау мөмкинлеге бирер. Ял көннәрендә әйбәт хәбәр ишетелер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Ялкаулык басмаса, бик күпкә ирешә алачаксыз. Атна уртасында көтелмәгән очрашу һәм танышу булырга мөмкин. Ничек тә күбрәк аралашырга, кая гына барсагыз да, игътибар үзәгендә калырга тырышыгыз. Ләкин гайбәткә ышанмагыз, юкса тиктомалдан якыннарыгыз белән араларны бозарга мөмкинсез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Башыгызга – шәп кенә планнар, күңелегезгә илһам килер. Өстәвенә бик күптәннән борчып килгән бер мәсьәлә дә искиткеч уңышлы хәл ителер. Әйбәт яңалыклар һәм мул гына керем көтегез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Бу атнада план белән яшәүнең яхшырак булуына төшендерердәй бер вакыйга килеп чыгар. Белеп торыгыз: кемнәрнеңдер проблемаларын хәл итәргә маташып, уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Шуңа күрә әлегә үзегезне генә кайгыртыгыз.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Озакка сузылган эшләрегезне уңышлы тәмамлап, җиңел сулап куярсыз. Әмма әлегә яңаларына тотынмау хәерлерәк. Кемнәрнеңдер җавапсызлыгы аркасында эшлекле мөнәсәбәтләр өзелергә мөмкин чөнки.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Уңай атна. Гәрчә сезгә берара күләгәдәрәк калып торырга туры килсә дә. Хәер, нәкъ менә шушы хәл сезгә әйбәт кенә файда китерәчәк тә. Хезмәттәшегезнең сер итеп әйткән сүзләре күңелегездә йөртелгән бер сорауга җавап булыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Тормышны уңай якка борып җибәрү мөмкинлеге чыгар. Сак булыгыз: бер адәмнең, астыртын гына елмаеп һәм яхшатланып, үзегезне төп башына утыртып калдыруы бар. Ял көннәрен матур гына түгел, табышлы да уздырырсыз.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бу атнада язмышыгызга уңай йогынты ясардай хәлләр килеп чыгар. Гомумән, тормышыгызда яңа юллар ачылыр. Ул гына да түгел: көтелмәгән вакыйга һәм... бер бүләк тә булыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Көндәлек эшләр һәм тормыштагы вак-төяк проблемалар белән мәш килерсез. Хафаланмагыз: алар сезгә күңел тынычлыгы китерү генә түгел, бәлки әле әйбәт кенә керемгә өмет-ышаныч та уятыр. Югарырак вазыйфага күтәрелү өчен искитмәле мөмкинлек ачылыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Күңелегез ярамаганрак эшләргә тартылыр. Шуңа күрә, адреналин артыннан куып, тормышыгызны боза күрмәгез тагы, дип кисәтмәкче йолдызлар. Атна ахырында күңелегезгә сары май булып ятардай бер яңалык ишетелер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Агымга каршы йөзмәгез, алгы планга чыгарга тырышмагыз. Шулай булганда, иң шәп нәтиҗәгә ирешәчәксез! Атна ахырында ишетелгән сәеррәк бер хәбәргә аптырап калмагыз: чынбарлыкка туры килми бугай ул...

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Киләчәкне кайгыртыгыз. Хәзер никадәр күбрәк тырышсагыз, алга таба шуның кадәр җиңелрәк булачак. Кем беләндер ачыктан-ачык сөйләшү күңелегездәге күп кенә сорауларга ачыклык кертәчәк.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы мелиораторлары һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы, Тукай районы сугару-киптерү эксплуатация идарәсе элекке башлыгы

ГЫЙЗДӘТУЛЛИН
Вахит Вәгыйз улы

кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӨРӘК БИЛГӘ БӘРМӘСЕН ДИСӘҢ...

Казу, тырмалау, чәчү, утырту, җыештыру... Соңгы арада көннәребез әнә шулайрак үтә. Кызу бакча чорына аяк бастык. Кыш буе артык хәрәкәтләнмичә яшәргә өйрәнгән организмыбыз өчен зур сынау чоры да бу. Бакча чорында организмга зыян килмәсен өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА бу уңайдан киңәшләрен бирде.

:: Бакча эшләре башланган чорда кемнәргә үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк?

– Бакча эшләре башлану белән артрит, остеохондроз кебек терәк-хәрәкәт аппараты авырулары баш калкыта. Озак вакыт бер торышта эшләү, авыр күтәрү, кисәк иелү-бөгелүләр организмга шул рәвешле тәэсир итә. Бу чорда кан басымы да еш күтәрелә. Бу исә инфаркт куркынычын арттыра. Кояш кыздырганда бакчада эшләсәң, эссе кагарга да мөмкин. Бакча эшләре вакытында тән тиресе җәрәхәтләнү очраклары да еш күзәтелә. Өлкән яшьтәге, хроник авырулары булган кешеләргә бу чорда үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк.

:: Бакчада тырышып эшләгәннән соң бил сызласа, бил «кузгалса», ни эшләргә?

– Бакчада эшләп кергәннән соң бил авырта башласа, каты, тигез өслеккә ятып, арканы, билне ял иттереп, язылдырырга кирәк. Авыртуны баса торган мазь, гельләр дә ярдәмгә киләчәк. Махсус күнегүләр дә ясый алясыз. Хәлегез аннан соң да уңайланмаса, авыру көчәя генә барса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бакчадагы эш билгә бәрмәсен дисәң, кисәк хәрәкәтләрдән, авыр әйбер күтәрүдән сакланырга кирәк. Берәр әйбер күчерергә кирәк булган очракта да кул арбасы яки тәгәрмәчле җайланмалар кулланса яхшы. Билгә корсет киеп эшләү дә файдага. Гел бер халәт-торышта гына эшләргә дә ярамый. Шуңа күрә бакча чорында эш белән ялны чиратлаштыру мөһим. 15–20 минут эшләгәч, бераз ял итеп алырга кирәк.

:: Бакчада көннең кайсы вакытында эшләү хәерле?

– Бакчада иртәнге һәм кичке якта эшләргә кирәк. Кояш кыздырган чакта, төшке аш вакытында бу эшне кичектереп тору хәерле.

:: Бу чорда муенга җил бәрү дә еш күзәтелә бит...

– Муенга җил бәрсә, коры, җылы компресс ярдәмгә килә. Шарф яки яулыкны үтүк белән җылытып, шуны муенның авырткан өлешенә куеп торырга кирәк. Җил бәргән урынны җиңелчә массажлау да авыртуны басачак. Алда телгә алынган чаралар ярдәм итмәсә, табибка күренергә кирәк.

:: Бакча чоры белән бергәттән хәзер күпләр җәйгә фигура «ясау» ягын да кайгырта. Көннәр җылыткач, йөгерергә чыгучылар саны артты. Йөгерү һәркем өчен дә файдалымы?

– Йөгерү бар кешегә дә килешми. Терәк-хәрәкәт системасы авырулары (артрит, артроз, остеопороз һ.б.) булган кешеләргә бу эштән тыелып торырга кирәк. Ник дигәндә, йөгергәндә буыннарга басым арта. Бу исә авыртуны көчәйтергә мөмкин. Йөрәк, кан тамыры авырулары булган, инфаркт, инсульт кичергән, бөер авырулы кешеләргә дә йөгерергә киңәш ителми. Ашкайнату системасы авырулары баш калкытканда, инфекцияле авырулар, эпилепсия вакытында да йөгерү тыела.

Гөлнара Зиннәтуллина

Бакчада эшләгәндә истә тотарга кирәкле киңәшләр

- ✓ Бакчада баш киемсез эшләмәгез.
- ✓ Бакчада иртәнге сәгать унга кадәр һәм кичке сәгать дүрттән соң эшләү хәерле.
- ✓ Физик эш башкарыр алдыннан бераз тәнне язып, җиңелчә генә күнегүләр ясап алу да комачауламас. Болай эшләгәндә, мускулларга авырлык килмәс.
- ✓ Берьюлы биш килограммнан да авыррак әйбер күтәрмәгез. Авырлык тигез төшсен өчен аны ике куллап күтәрү яхшырак. Авыр әйберне кисәк тотынмыйча, утырган килеш – авырлык билгә түгел, аякларга төшәрлек итеп, җайлап кына күтәрергә кирәк. Көрәкнең дә озын саплысы белән эшләсәң яхшырак.
- ✓ Бакчада эшләгәндә чиста суны пыяла савытта сакларга кирәк. Кояш кыздырганда пластик шешә җылына һәм аның составындагы зарарлы матдәләр суга да күчәргә мөмкин.
- ✓ Бакча чорында эш белән ялны чиратлаштырырга онытмагыз. 15–20 минут эшләгәч, бераз ял итеп алырга кирәк.
- ✓ Гигиена таләпләре дә истән чыкмасын. Нәрсә дә булса ашар, алып кабар алдыннан куллар чиста булырга тиешлеген онытмагыз.

Исеңдә тот!

Гемоглобинны күтәрим дисәң...

→ Бер үк күләмдә яңа сыгылган кара торма, кишер, кызыл чөгендер, гранат сокларын бергә болгатыгыз. Банкага бушатып, өстен каплап, 3 сәгать җылы духовкада төнәтегез дә суынгач сөзегез. Сыеклыкны өсте ныклап ябылган савытта суыткычка куеп сакларга кирәк. Аны 2–3 ай дәвамында көнгә 3 мәртәбә ашарга ярты сәгать кала 2–3 аш кашыгы эчәргә киңәш ителә.

→ Тагын бер төнәтмә: 1әр аш кашыгы вакланган миләш һәм гөлҗимешкә ике стакан кайнар су агызалар. Шуны сүрән утта 5 минут кайнаталар. Савытны калын сөлге белән төрәп, бер тәүлек тоткач сөзәләр. Аз гына бал салырга була. Төнәтмәне көнгә 3–4 мәртәбә ашар алдыннан яртышар стакан эчәләр.

АЯКНЫҢ ТӨП ДОШМАНЫ

Дөрес сайланмаган җәйге аяк киеме аяк табанына зыян салырга мөмкин, ди травматолог-ортопед Михаил Вихтар. Табиб сүзләренә караганда, табанда хилафлыклар булу бөтен организмга тискәре йогынты ясый. «Җәй көне аяклар өчен төп дошман – сланцы. Аяк киеме табанының материалына да игътибар итәргә кирәк. Ул артык биек булмасын. Җәй көне шәһәр читенда яки паркта яланаяк йөреп була. Аякларны табигый халәттә йөртү бик яхшы. Моңа йога ярдәм итә», – дип киңәш иткән табиб.

Гомуми кан анализы: күрсәткечләр нәрсә турында кисәтә?*

НОРМАДАН ЮГАРЫ	КҮРСӘТКЕЧЛӘР	НОРМАДАН ТҮБӘН
– кан куе, тромб килеп чыгу куркынычы зур; – шикәр чире; – йөрәк эшчәнлегенең җитенкерәмәве	**Гемоглобин** 120–140 г.л (хатын-кызлар) 150–160 г.л (ир-атлар)	– анемия; – организмга тимер җитмәү; – кан киту куркынычы зур
– В төркеменә керүче витаминнарга, фолий кислотасына кытлык	**Эритроцитлар** $3{,}9–4{,}7\times10^{12}$(хатын-кызлар) $4–5\times10^{12}$ (ир-атлар)	– ашказаны-эчәк тракты авырулары; – лейкоз
– хроник ялкынсыну бар; – инфекцияле авырулар; – кандагы кислород күләме киму (гипоксемия); – яман шеш	**Лейкоцитлар** 4–9×109 (ир-атлар)	– яңа күзәнәкләр булену өчен кирәкле матдәләр (фолий кислотасы, тимер, В төркеменә керүче витаминнар, бакыр һ.б.) җитмәү; – агулану; – вируслы яки бактериаль инфекция
– туберкулез; – кан авырулары; – бавыр һәм бөер яман шеше; – артрит; – энтерит; – кискен инфекцияләр	**Тромбоцитлар** $150–400\times10^{9}$	– гепатит; – цирроз; – калкансыман биз авырулары; – экчечелек
– ялкынсыну процесслары; – агулану; – кискен һәм хроник инфекцияләр; – миокард инфаркты; – җәрәхәт һәм сынулар; – яман шеш	**СОЭ** 2–12 мм/с (хатын-кызларда) 2–15 мм/с (ир-атларда)	– организмда су-тоз алмашы бозылу; – тукыма һәм мускулларның тукылануы бозылу

**Кан анализы күрсәткечләрен табиб кына тикшерергә тиеш.*

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

БУРЫЧТАН КОТЫЛЫЙМ ДИСӘҢ

Икътисадтагы тотрыксызлык, санкцияләр аркасында күпләр киләчәк керемнәрен фаразлый алмый. Үзәк федераль округ буенча Үзәк банк идарәсе баш икътисадчысы Александра ЛЬВОВА санкция шартларында барлык бурычларны тизрәк ябарга тырышырга кирәк дип саный. Ә Үзәк банк кредитлардан котылуның биш ысулын атады.

Илдар Мөхәммәтҗанов

✓ **РЕФИНАНСЛАУ.** Бу – булган кредитны ябу өчен икенче кредит алу дигән сүз. Әлеге программа кредит ставкасын киметергә, түләү вакытын озайтырга яки айлык түләүне киметергә мөмкинлек бирә. Әгәр югары ставка белән кредит алгансыз икән, ставкалар төшкәч, аны рефинанслагыз. Әгәр кредитыгыз берничә булса, аларны берләштерергә мөмкин.

✓ **КРЕДИТНЫ АЛДАН ЯБУ.** Кредитны вакытыннан алда ябу аның вакытын кыскартырга һәм процентларда экономияләргә мөмкинлек бирә. Вакытыннан алда түләгәндә процентлар кредиттан файдаланган вакыт өчен генә түләнә. Закон буенча кредитны вакытыннан алда түләү өчен әлеге карарың турында банкка кимендә 30 көн алдан хәбәр итәргә кирәк, тик банк үз заемчылары өчен азрак вакыт билгеләргә мөмкин. Шулай ук вакытыннан алда түләп бетерү мөмкин булган минималь суммага да игътибар итәргә кирәк. Әгәр вакытыннан алда бурычның бер өлеше генә түләнсә, банк түләүнең яңа графигын җибәрә.

✓ **ЗАПАСЛАРНЫ БАРЛАУ.** Ремонт, ял, яңа кухня өчен җыеп барган акчаны кредит ябу өчен тотарга мөмкин. Әмма эштән кыскартылу була калса яки авырып киткән очрак өчен резерв калдырырга кирәк. Финанс куркынычсызлыгы мендәрен банкта саклау яхшырак. Депозитлар буенча ставкалар хәзер 16–18 проценттан да ким түгел. Кредит ябу өчен күчемсез милек яки машина сатарга ашыкмагыз.

✓ **«КЫЙММӘТЛЕ» БУРЫЧЛАРДАН АРЫНУ.** Әгәр югары ставкалы кредитларыгыз булса, иң беренче аларыннан арынырга тырышыгыз. Гадәттә, алар аз вакытка алынган кредитлар була. Әгәр күләме дә азрак булса, зуррак кредитларыгызны түләү җиңелрәк туры килсен өчен, анысыннан арынсагыз яхшырак булыр.

✓ **ПЛАН КОРУ.** Күпләр озак вакытлы финанс планнары төзи. Финансларны кыска вакытка планлаштырырга киңәш итә белгечләр. Банк кушымтасында чыгымнарны күзәтеп бару да комачауламый. Финансларны планлаштыру буенча башкалар тәҗрибәсен куллану да зыян итмәс. Японнар гаилә бюджетын алып бару буенча Kakebo системасын уйлап тапкан, анда тege яки бу әйберне берьюлы сатып алмаска киңәш ителә. Сатып алуны күпмедер вакытка кичектереп торасың, аннары бу чыгымның урынлы яки урынсыз түгелме икәнлеген тагын бер уйлыйсың.

Кредит түләүдә чыннан да кыенлыклар туса, банктан кичектереп торуны сорарга кирәк. Әгәр сезнең керемегез 30 процентка кимесә, закон буенча агымдагы елның 30 сентябренә кадәр ярты елга кредит каникулы рәсмиләштерергә мөмкин.

Үзем сынадым

Кыяр төшә башлау белән орлыкка кыяр калдырырга ашыкмагыз. Чөнки ул, кыяр үсентесен хәлсезләндереп, уңышы начараюга сәбәпче булачак. Кыярны бик өлгергәнче җыеп алу да аның уңыш бирү вакытын озайта. Элек кыяр төшүгә беренче кыярлардан ук орлыкка калдыра идем, минем хатамны кабатламагыз.

Алсу ВӘГЫЙЗОВА.
Кукмара

Сорау – җавап

Сорауларга бакчачы Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

:: Көзге ярминкәдән гортензия куагы сатып алып, чүлмәккә утырткан идем. Бүлмәдә башта әйбәт кенә утырды, әмма кышын пәрәвез сарган кебек чирләде...

Фирая ХӘЕРОВА.
Саба районы

– Аны утыртасы түгел, идән астында яки башка салкынча урында саклыйсы иде. Пәрәвез белән каплангач, пәрәвез талпаны белән зарарланган булгандыр. Чүлмәктә үсми ул. Бакчага күчереп утырткач, яңарып китәчәк. Ботакларын, астан 3–4 бөре калдырып, кисәргә кирәк. Шунысы да бар: гортензия әче туфрак ярата.

:: Пекин кәбестәсен теплицага кайчан утыртырга? Чәчәккә китмәсен өчен нишләтергә?

Резеда ИБРАҺИМОВА.
Мамадыш районы

– Гадәттә аны теплицада түгел, ә ачык туфракта үстерәләр. Кәбестәнең бер төре генә бит ул. Редиска кебек, көн озынлыгы кыскарак булганда, салкынчарак вакытта әйбәт үсә. Чәчәккә китмәсен өчен, яфракларын җыеп, резинка белән әләктереп куярга кирәк.

Тәмле булсын!

Алмалы төенчекләр

Дания ДӘҮЛӘТҖАНОВА рецепты

Камыр өчен: *150 г атланмай, 150 г каймак, 50 г шикәр комы, 2 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч, 1 пакет ванилин, 350 г чамасы он.*

Эчлек өчен 6–7 алма, өстенә сылау өчен бер йомырка сарысы кирәк була. Йомшак эластик камыр әзерлибез. Камырны җәеп, уртасына ярты алманы салып (корица да сибәргә мөмкин), төенчекләр ясыйбыз. Аннары аны йомырка сарысы белән «майлап», өстенә шикәр комы сибеп, 180–190 градуслы мичкә 40 минутка озатабыз. Бик тәмле була!

Бакчачыга

АШ СЕРКӘСЕ ЧИСТАРТА

Блогер Наталья ГЫЙЛӘҖЕВА, аш серкәсен ризык пешергәндә генә түгел, ә көнкүрештә дә бик яратып кулланам, ди.

✷ Ике атнага бер тапкыр җылымса суга 6–7% аш серкәсе салып, суыткычны сөртеп торсаң, анда бернинди тәмсез ис тә булмаячак.

✷ Спорт киемнәрен юганда да аш серкәсе төп ярдәмче. Кер машинасына 9 процентлы 100 мл аш серкәсе салсагыз, ике куянның койрыгын бергә тотасыз дигән сүз. Бердән, киемдәге тәмсез исне бетерә, икенчедән, кер юу машинасына дезинфекция ясыйсыз.

✷ Ул киемдәге тир һәм дезодорант эзен бик яхшы бетерә. Таплы урынга салып бераз тотсагыз, тапның эзе дә калмаячак. Ефәк тукымалар искәрмә булып тора.

✷ Чәйнек, су савыты, вазадагы юшкынны да бик яхшы бетерә.

✷ Ирригатор белән кран авызы тишегендәге юшкынга сиптерен тотсагыз, бераздан бик ансат юылып төшәчәк.

✷ Шулай ук киемгә ябышкан сагызны да серкә ярдәмендә бетерергә була.

Аш серкәсенең исе начар дип борын җыермагыз, аның исе бик тиз очып бетә. Ә кулланганда кулыгызга пирчәткә киярга онытмагыз.

Белен тор!

Таба кайнатабыз

Әлеге ысул бәләеш табаларын чистарту өчен яхшы. 10 л суга ярты кап чәй содасы, бер кер сабыны, бер савыт кәгазь җилеме салып, табаларны кайнатырга куярга кирәк. Бер сәгатьтән тимер мунчала белән бик ансат кына чистартылырлар. Ә чистарып бетмәгән урыннары калса, тагын 30–40 минут кайнатып алырга. Майга каткан табалар шулай иткәннән соң, чип-чиста булырлар.

ЧАМА ХИСЕ ЮГАЛМАСЫН

Матурлык корбаннар сорый, дияргә яратабыз. Әмма аның артыннан куып, еш кына чама хисе дә югала. Матур йөз, буй-сын, тышкы кыяфәткә ирешү өчен, кыйләр гадәтләреннән генә түгел, ризыктан да баш тартырга әзер. Соңгы арада көннән-көн популярлаша барган ябыгу марафоннарына ихтыяҗның зур булуын да шуның белән аңлата белгечләр. Динебез бу күренешкә нинди мөнәсәбәттә соң? Үзеңне ниндидер кысага кертеп ябыгырга тырышу гөнаһ түгелме?

Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт ЗӨФӘРОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Бүген табиб-диетолог, блогер, хәтта җырчыларга кадәр, ябыгу марафоннары оештырып, тиз арада сылу буй-сынга ирешүне вәгъдә итә. Дин бу күренешкә нинди мөнәсәбәттә? Ашау ягын чикләп, үзеңне ниндидер кысага кертеп ябыгырга маташу гөнаһ түгелме?

– Шундый заманда яшибез: табыннарыбыз ризыклардан сыгылып тора. Хәтта гади генә мәҗлескә барсак та, каршыбызда ничә төрле ризык күрәбез. Бу – Аллаһ Раббыбызның рәхмәте. Әмма бүген адәм баласы шушы ук ризыкларның күплеге белән сынала да. Динебез ислам һәрвакыт үзебезне карап, тәрбияләп торырга өйрәтә. Исәнлек-саулык та, тормыш-хәятебез дә, Аллаһы Тәгалә биргән ризык та – әманәт. Кеше менә шушы әманәтне үтим, сәламәтлегемне кайгыртам дигән ният, хәерле максат белән ризык күләмен чикли, аны хисаплап, контрольдә тотып ашый икән, моның зыяны юк. Әмма чама хисен дә онытырга ярамый. Әгәр диеталар, ябыгу марафоннары адәм баласының тормыш мәгънәсенә әверелсә, алар аркасында гаиләсенә, балалары, җәмәгате, туганнары белән мөнәсәбәтләренә зыян килсә, аны ялгыш юлларга кертеп җибәрсә, динебез бу нәрсәне хупламый. Без аны бер төрле күркәмлек илә максат итеп файдаланырга тиешбез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу гәләйһи вә сәлләм гомерендә бер тапкыр да туйганчы ак ипи ашый алмаган. Бер карасаң, ул олы бер дәүләт башлыгы, Аллаһның сөеклесе булган. Сәхабәләре дә аның өчен җан атып торган. Әмма рәсүлебезнең өендә кайчак айлар буе учак ягылмаган, ягъни кайнар ризык әзерләнмәгән. Ул, хөрмә ашап, су белән көн күргән. Пәйгамбәребезнең ашау-эчү, ризыкка мөнәсәбәтен әнә шуннан чамаларга мөмкин. Күп ашау кешенең тәненә генә түгел, сәламәтлегенә, акылына да зыян китерә. Аллаһы Тәгаләбез дә Коръәндә: «Ашагыз, эчегез, исраф итмәгез», – ди. Шуңа күрә динебез бу мәсьәләдә алтын урталык яклы.

:: Адәм баласы ризыкларның күплеге белән сынала да, дидегез. Сайлануыбыз, үзебезне мәҗбүр итеп, ризыктан баш тартуыбыз белән шушы сынауны үтә алмыйбыз, димәк?

– Аллаһы Тәгалә безне төрлечә сыный шул. Кемнедер ризыксызлык, кемнедер муллык, байлык белән сыный. Адәм баласының ризыкның кадерен белмәве Аллаһы Тәгалә каршында хәерсез гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә безгә ризык насыйп итмәсә, аны кем бирер иде? «Кесәмдә акчам бар, теләгән әйберемне сатам да алам», – дип уйлый алабыз. Әмма Раббыбыз юлларын ябып куйса, шул ук басу-кырларда яңгыры булмаса, игеннәр үсмәсә, үсеп тә, шуны җыеп ала алмасак, табыннарыбызга ризык, ипи халәтендә килеп ирешә алмаса, бу нигъмәт кайдан килер иде? Шуңа күрә без Аллаһы Тәгалә насыйп иткән ризыкны кабул итеп, исраф итмичә, аның кадерен белергә тиеш. Рәсүлебез заманында да ачлыктан эчләренә ташлар бәйләп куючылар булган. Хәдисләрдән аңлашылганча, пәйгамбәребезнең сәхабәләренең ачлыктан йоклый алмыйча урамнарга чыккан вакытлары да булган. Аллаһы Тәгалә безгә аның Коръәни Кәримдәге аятьләре аша бәян итте. Шуңа күрә без бу мәсьәләдә бик игътибарлы булырга тиеш. Ризыкны исраф итмичә, күршеләребез, якыннарыбызның хәл-әхвәлләрен белеп яшәргә кирәк. Рәсүлебез дә: «Үзе тук йоклап, күршесе ризыксыз утыра икән, бу кешенең халәте нинди? Иманы камилме икән?» – дигән.

:: Артык авырлыктан котылу, зифа буй-сын өчен ашамыйча тору, диета тоту кебек күренеш пәйгамбәребез яшәгән чорда да булганмы?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу гәләйһи вә сәлләм ризык мәсьәләсендә юлларын күрсәтте. Әйтик, ашаган-эчкән вакытта ашказанын өчкә бүлегез, дигән ул. Ризык белән судан тыш һавага да урын калдырырга куша. Моны буй-сыннан бигрәк, җан һәм тән саулыгы өчен эшләргә онди. Бүген боларны үтибезме соң? Юк! Ризык күп булгач, бер-беребезне кыстый-кыстый ашыйбыз, хәтта һавага да урын калмый. Кеше белән күрешү, аралашуны да еш кына ризыкны шыплап тутыруга кайтарып калдырабыз. Пәйгамбәребез ризыкны «бисмилла» әйтеп, уң кул белән дә ашарга өйрәтте, ризык кулдан төшеп китсә, аны өреп кабып, барыбер ашарга кушты. Ул йөгереп тә караган, мәчеткә җәяү бара-кайта торган булган. Без бу дөньяда яшәү өчен ашарга тиешбез!

:: Соңгы вакытта глютенсыз диеталар аеруча популярлашып китте. Глютен – иң беренче чиратта, икмәк дигән сүз. Димәк, бездә икмәк кадере, ризык кадере дә кими булып чыга?

– Глютен мәсьәләсендә төрле фикер ишетергә туры килә. Әмма үзеңне шушы матдәдән чикләүнең әлләни зыяны юк. Глютен бер кешенең организмына зыян салса, икенчесенә файда китерәдер. Шуңа күрә табиб ризыкны башкачарак кулланып карарга киңәш итә икән, моңа колак салырга кирәк. Әмма шул ук вакытта «кешегә глютенлы икмәк ашарга ярамый» ише сүзләрне дә кычкырып йөрергә кирәкми. Без бу мәсьәләдә дә урталыкны сакларга тиеш. Әмма глютенны чикләүне икмәк кадере кимү дип карарга кирәкме икән? Безнең әби-бабайлар ул икмәкне туйганчы ашый алганнармы? Юк, әлбәттә. Ә безне Раббыбыз Аллаһ икмәкнең күплеге белән сыный. Бүген аның нинди генә төрләре юк. Көндәлек тормышыбызда алган ипи кибеп, корып яткан, хәтта кеше аны чыгарып ук ташлаган очраклар байтак. Икмәк кадере күбрәк әнә шундый очракларда кими. Күп әйбернең кадере юк. Шуңа күрә әгәр адәм баласы икмәкне санап, кадерләп, тиешенчә генә ашарга тырыша икән, моның бер зыяны да, гөнаһы да юк.

:: Ислам дине нутрициологларга, нутрициологиягә нинди мөнәсәбәттә?

– Ризык күп булганга күрә, кеше чамадан тыш ашый, туклана. Шуңа бәйле рәвештә төрле авырлык-мәшәкатьләр барлыкка килә, төрле авырулар пәйда була. Ризык мәсьәләсендә фән алга барган саен, төрле белгечләр дә барлыкка килә. Нутрициологларны нинди ризык, нинди матдәнең кешегә ничек тәэсир итүен, кайсының күбрәк, кайсының азрак кирәк булуын билгели торган белгечләр дип беләбез. Әлбәттә, моннан зыян юк. Әгәр алар бу исемне генә күтәрмичә, табиблык белгечлеге алган, моңа махсус укыган икән, бик яхшы. Әмма моның икенче ягы да бар. Аларның төп максаты кешеләргә ярдәм итү булырга тиеш. Әгәр ул кесәсен калынайту өчен генә эшли икән, бу – зур гөнаһ. Күреп торабыз: бүген арабызда андый затлар бик күп. Һәркайсы, егылып китеп, үз хезмәтен, үз препаратларын мактый. Ислам – сәламәтлек дигән сүз. Динебез күңелләребезнең дә, ашаган ризык, торган җиребезнең дә сәламәт булуын тели. Шушы максатта хезмәт иткән белгечләр дә иң беренче чиратта Ходай Тәгалә тарафыннан билгеләнгән шушы олы бурычны истә тотып эш итәргә тиеш.



pixabay.com

Белә идегезме?

Сәлам саен савап

Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килеп, аны: «Әссәламү галәйкүм» дип сәламләгәч, Мөхәммәд сәламгә җавап биргән һәм: «10», – дип әйткән. Икенче кеше килеп: «Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһ», – дип исәнләшкән. Мөхәммәд сәламгә җавап биреп: «20», – дип әйткән. Тагын бер кеше килеп: «Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ», – дип сәлам биргәч, Мөхәммәд бу кешегә дә җавап биргән һәм: «30», – дип әйткән.

Шунда булган мөселманнар пәйгамбәр галәйһи вә сәлләмнән 10, 20, 30 саннарының мәгънәсен аңлатып бирүен үтенгәч, ул: «Беренче кешегә – 10 савап, икенчесенә – 20, өченчесенә 30 савап язылды», – дип җавап биргән.

Сәламләү сүзләреннән тыш, ислам динендә сәлам бирүгә бәйле кайбер кагыйдәләр дә каралган, мәсәлән, транспорт (машина) эчендәгеләр – җәяүлеләргә, үтеп баручылар – утырганнарга, ялгыз кеше – җәмәгатькә, кечерәк яшьтәгеләр өлкәнрәкләргә беренче сәлам бирергә тиеш. Хәдистә: «Аттагылар – җәяүлеләргә, үтеп баручылар – утырганнарга, аз санлылар – күп санлыларга, балалар олыларга сәлам бирергә тиеш», – дип әйтелә. Хәдисләрдән Мөхәммәднең балаларга сәламне беренче үзе биргәне дә билгеле. Мәсәлән, Әнәс риваять иткән бер хәдистә болай диелә: «Мөхәммәд бала-чагалар яныннан үтеп киткәндә, аларга сәлам бирә иде».

3 хәдис

➤Кеше сөйләшкәнне тыңлап торучының колагына үлгәннән соң кургаш агызырлар.

➤Аллаһның ризалыгы – әти-әни ризалыгында. Аллаһның ачуы – әти-әни ачуында.

➤Яхшы эшләр эшләү кешене яман язмыштан саклый.



Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

СҮРЕЛМӘСЕН ГАИЛӘ УЧАГЫ

15 майда Халыкара гаилә көне билгеләп үтелә. Әлеге бәйрәм алдыннан «Ни хәл?» сәхифәсенә танылган гаиләләрне кунакка чакырып, бәхетле гаилә кору серләре турында сораштык.

«ИР – ИР УРЫНЫНДА, ХАТЫН ХАТЫН УРЫНЫНДА БУЛСЫН»

Данил СӘФӘРОВ, журналист:

– Аларны бер түгәрәктән икенчесенә йөртәбез, балачактан мәхрүм итәбез, алар бер-берсе белән аралаша алмый. Түгәрәккә йөртергә кирәк, әмма чик булырга тиеш. Балалар моннан газап чигә. Мәктәп бакчасыннан ук невроз башлана, – ди белгеч. – Ишегалдында уйнамыйлар, тауда шумыйлар. Барса да, кемдер озата. Янәшәсендә – әнисе. Бала инфантиль була, ягъни мөстәкыйльлегә булмый, нишләргә кирәклеген белми. Без гел басым ясап торабыз. Әгәр бала шаугөр килеп уйнаса, дуслары белән аралашса, арып ятып йокласа, бу – психотерапия. Бала ял да итәргә тиеш. Вакытын бушка үткәрмәгән саен яхшырак дип уйлыйбыз. Бала, киресенчә, суына, аңа начар, аны күрмиләр, ишетмиләр. Ул башкаларның авыртуын, борчуын сизми. Мәктәптә гиперактив балалар күп. Алар яхшы укый, әмма укытучыга җайлы түгел. Йә ул партадан нәрсәдер эзли, йә бер урында тик тормый. Әгәр без җирән кешегә, син иртәгә ак булып кил, дисәк, ул үзгәрә алмый. Бала да тәртибен шундук ничек үзгәртә алсын? Укытучыларга вузда мондый балалар белән ничек эшләргә кирәклеген аңлаталар. Тик алай эшләү мәшәкать. Син – сугыш чукмары, начар, дип гел әйтеп торсалар, әлбәттә, агрессия башланачак. Укытучы һәр бала белән уртак тел таба белергә тиеш. Бу очракта игътибар юнәлтергә кирәк. Әгәр аны аңламасаң, күңеленә бар үпкә җыелачак: мине мәктәптә чит күрәләр, өйдә мине әни орыша, дусларым юк, дип үзен кирәксез хис итәчәк. Кем белән аралашырга? Әлбәттә, интернет кала. Виртуаль дөньяда үсмер чынбарлыктан китә.



МЕДИЦИНА ПСИХОЛОГЫ ЛЮДМИЛА НЕВОСТРУЕВА КИҢӘШЛӘРЕ

- Бала белән рәхәтләнеп аралашырга кирәк. Гаиләдә рәхәт булса, бала да тыныч булачак.
- Гаилә традицияләрен булдырыгыз. Бергә пирог пешереп, өйдәге якыннарның туган көнендә сюрприз ясарга, әбигә кунакка барырга була.
- Артык борчылудан да файда юк. Бер әбинең 16 яшьлек оныгының ботинка бавын бәйләгәнен күрдем. Ник бәйлисез, бәйләмәгез, дим. Мәктәпкә дә илтәбез, букчасын да тутырабыз, ди.
- Балагызга көче җитмәслек таләпләр куймагыз.
- Хезмәт тәрбиясе, спорт, рәсем дәресләре бик файдалы.
- Мәктәпләрдә психологлар штаты түбән. Һәр сыйныфта, атнага бер мәртәбә булса да, психология дәресе укытылсын иде.
- Без баланы таптык, ашатабыз, эчертәбез, калганын бакча, мәктәп тәрбияләсен, дип кул селтәү – ялгыш фикер.

Быел март аенда Татарстан һәм Чуашстан республикаларында Бөек Ватан сугышы елларында Казан каймасы һәм Сура оборона сызыгы төзелешe тәмамлануга 80 ел булу уңаеннан һәм төзүчеләрнең хезмәт батырлыгына багышлап, «Тылдагы батырлык» дип аталган төбәкара патриотик марафон башланган иде. Ай дәвамында ике республикада да искә алу чаралары узды. 11 майда Габдулла Тукай исемендәге Казан дәүләт филармониясендә марафон тәмамлану уңаеннан тантаналы шартларда концерт булды, фойеда күргәзмә эшләде. Рөстәм Миңнеханов тамашачыларны һәм марафонда катнашучыларны Җиңү бәйрәме белән котлады, оештыручыларга, тарихчыларга рәхмәтен җиткерде. Чуашстан Республикасы башлыгы Олег Николаев шулай ук тылда хезмәт итүчеләрнең батырлыгын төрле ысуллар белән яшь буынга җиткереп торырга кирәклеген искәртте.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Халкыбызның бу батырлыгы хәтерләрдән җуелмасын өчен ниләр эшләргә? Кайбыч районы башлыгы урынбасары Рамис ХӘЯЛИЕВ белән шул хакта сөйләшәбез.

КАЗАН КАЙМАСЫ

:: Рамис Рафисович, хәтерләсәгез, без сезнең белән моннан 10 ел элек, Казан каймасының төзелеп бетүенә 70 ел булу уңаеннан, окоп казучылар эзен барлап, «сәяхәт кылып» йөргән идек. Минем үз әнием дә, яшь ярымлык баласын – абыемны күршеләрдә калдырып, шушы җирләрдә кулына көрәк, кәйлә тотып эшләгән. Аның сөйләгәннәрен дә бик яхшы хәтерлим. Шул вакытта сез: «Казан каймасын төзүчеләр зур батырлык кылган. Без моны киләчәк буыннарга да түкми-чәчми җиткерергә тиешбез», – дигән идегез. Ниләр үзгәрде?

– Кызганыч, без соңгарак та калдык кебек. Окоплар белән кызыксыну 2000 нче елларда гына башланды. Ни өчен болай килеп чыкканын әйтә алмыйм. Югыйсә сер итеп тә сакланмады бит ул. Иң төп сәбәп – мөгаен, битарафлыктыр. Хәтерлим, узган гасырда һәр өйдә диярлек окоп казучылар исән иде әле. Хәзер бөтен районга ун гына кеше калды. Районда бу темага ел саен фәнни-гамәли конференция уздырыла. Анда күрше районнардан, хәтта башка республикалардан да катнашалар. Казан каймасына багышлап, Олы Кайбыч һәм Иске Чәчкаб авылларында һәйкәлләр төзедек. Илебез тарихында тиңе булмаган бу хезмәт батырлыгын чагылдыру өчен болар гына җитми, әлбәттә. Башкарасы эшләр күп әле.

:: Сез Җиңү көненә әзерләнү һәм үткәрү чаралары буенча Республика оештыру комитетының Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган утырышында Казан каймасы турында чыгыш ясаган идегез. Саллы гына тәкъдимнәр дә әйтелде. Укучыларыбызны да таныштырыйк әле.

– Сугыш вакытында безнең якларда төзелгән бу объектларны, тарихи һәйкәл буларак, мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертү кирәк дип уйлыйм. Окопларның аерым бер участогын төзекләндереп, яңартып, оборона сызыгы итеп торгызу турында хыялыбыз бар. Бу гамәл тарихи урынны яшь буынга, халыкка күрсәтү, күргәзмәләр оештыру, туристлык объектына әйләндерү өчен кирәк. Илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүчеләрне чакырып, төбәкара фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү, китаплар чыгару, документаль фильм төшерү ихтыяҗы да көн кебек ачык.

:: Минемчә, бу тәкъдимнәрне тормышка ашыру барышында Кайбыч районы төп рольне уйнар кебек. Ни өчен?

– Казан каймасының 60 чакрымы безнең районга туры килә. Безнең территориядә аның эзләре ныграк сакланып калган. Форсаттан чыгып, шуны сын да әйтик: бу окоплар Татарстанда гына түгел, ә Идел буендагы башка шәһәрләрдә дә казыла. Ул Идел буе оборона сызыгы дип атала. Гомуми озынлыгы 2 мең чакрымны тәшкил итә. Татарстан территориясендәгесе хәрби телдә Казан оборона сызыгы дип йөртелә. Казан каймасы – халык биргән исем. Кайбыч тирәсендә оборона сызыгы иң тирән эшелонлы, ныгытмалы итеп корыла. Гади халык белән бергә саперлар да эшли. Җирне шартлату, инженерлык хезмәте югары дәрәҗәдә оештырыла. Немец танклары килеп җитсә, дуганың уртасына һөҗүм итәрләр дигән фикер булган. Чөнки бу урында – Мәскәү юлы. Хәзерге вакытта төзелүче М12 трассасы да нәкъ шушы Иске Чәчкаб, Олы Кайбыч авыллары янәшәсеннән уза. Төп төзү участоклары хәрби-кыр төзелеше дип аталган. Беренче номерлы төзелеш штабы Иске Чәчкаб авылында урнаша. Шуңа күрәдерме, бу эшләр безнең якта тагын да кискенрәк төс алып, эзе дә тирәнрәк калганга охшый. Мин үзем дә шушы авылдан. Халык телендә окоплар дип аталган бу чокырларда ничә буын малайлар уйнап үсте. Әти-әни, әби-бабайлар да бу хәлләр турында гел сөйләп торды.

:: Казан каймасы турында шушы көнгә кадәр төрле фикерләр ишетелә. «Халыкны азаплап, бер кирәкмәгән эш эшләткәннәр», – диючеләр дә очрый.

– Үземә дә бу сорауны бик еш бирәләр. Җавабым бер: дошман безгә килеп җитмәс дигән бер генә ышаныч та булмаган. Бу зур оборона сызыгының төп максаты – дошманны Идел буенда туктату, Урал сәнәгать зонасына җибәрмәү. Өстәвенә Казан, Яшел Үзән шәһәрләренә дә Мәскәү белән Ленинградтан иң мөһим сәнәгать предприятиеләре эвакуацияләнә.

:: Бу кадәр авыр шартларда туң җирне казу өчен нинди көч кирәклеген аңлау да кыен. Ә монда эш берниндн техникасыз, көрәк, кәйлә белән башкарылган. Ир-атлар фронтта. Халыкны ничек туплап бетерә алганнар?

– Окоп казу эшләре нигездә хатын-кызларга бәйле. Нинди генә шартлар булуга карамастан, безнең якларда гаиләдән бер кеше кулына көрәк алып, мәҗбүри төстә эшкә чыгарга тиеш булган. Димәк, бу фаҗига һәр йортка кагылган дигән сүз. Төзелешне башлау турындагы боерык 1941 елның октябрендә кабул ителә. Шундук окоп казырга Татарстанның шәһәр-районнарыннан эшчеләр килә башлый. Мобилизация бик көчле оештырыла. Якындагы Буа, Апас, Кайбыч, Норлат (хәзер Яшел Үзән составына керә) районнары төзелешкә унар мең кеше җибәрергә тиеш була. Ераграк районнарга норма азрак бирелгән. Мисал өчен, Балтачка – 3 мең, Чепьяга – 2 мең кеше. Казанга 83 меңнән артык эшче җибәрү бурычы куела.

> Планда төзелешкә 37 районнан 300 меңгә якын кеше җибәрү карала. Бу кадәр халыкны туплау, әлбәттә, зур кыенлык тудыра. Нәтиҗәдә Буа, Кайбыч районнарының нормасы 6 мең кешегә кала. Казан шәһәре планда каралганның яртысын гына җибәрә ала. Арада иң ерак район Әгерҗедән дә, Мәскәү һәм Ленинградтан килүчеләр дә була.

Килеп төшүчеләр арасында салкыннан авырып китүчеләр дә күзәтелә. Сугыш чоры законнары кырыс булса да, качып китү очраклары да теркәлә. Төзелештә даими рәвештә 100 мең һәм аннан да күбрәк кеше эшләгән. Окоп казуда табиблар, студентлар, хәтта Гыйлем Камай кебек күренекле галимнәрнең дә катнашуы билгеле. Казан дәүләт университеты һәм башка уку йортлары тулысы белән безнең якка эшкә җибәрелә. Университет ректоры Кирилл Ситников эш барышы белән шәхсән үзе җитәкчелек итә.

:: Бу кадәр халыкны яшәү урыны белән тәэмин итәргә, ашатып эчерергә дә кирәк...

– Эшкә килгән халык, районның тирә-як авылларына таралып, шәхси йортларда күмәкләшеп яши. Җирле халыкның өе кысан булса да, күңеле киң булган. Әби-бабай мич башына, бала-чага сәндерәгә күчә. Фатирга кергән халык, салам җәеп, идән тутырып йоклый. Өс һәм аяк киеме, ашарга ризык, ягарга утын, эш кораллары – барысы да җитәр-җитмәс кенә була. Әбәт ашатырга кухня әмәлләләр, үзенә күрә кибете дә була. Машиналар белән азык-төлек ташыйлар. Шул ук вакытта чагыштырмача җылы октябрь атлап йөрмәслек ноябрьгә, аннары 40–50 градуслы салкын декабрьгә алышына. Мондый шартларда үсмер егет-кызлар, яшь балаларын өйдә калдырып килгән аналар, 60ка җиткән ирләр ничек эшләгән? Ике кубометрга якын җир казу нормасын ничек үтәгән? Моны күз алдына да китереп булмый.

:: Тарих битләреннән күренгәнчә, шундый кырыс шартларда да окоп казучыларның кәефе оптимистик рухта булган...

– Андый очраклар да бар. Шул җәһәттән бер мисал китереп узам. Штаб урнашкан Иске Чәчкаб авылында бөтен Татарстанга танылган иҗат әһелләре эшли, башкалар кебек туң җир казый. Алар арасында Гомәр Бәширов кебек танылган язучылар да булган. Бригадирлары – Гадел Кутуй. Авыр эштән арган көннәренең берсендә ул композитор Җәүдәт Фәйзигә мөрәҗәгать итә. «Гел болай күңелсезләнеп йөреп булмый бит инде. Күңелне күтәрә торган берәр әсәр язасыңмы әллә?» – ди. Бу фикер бик тиз тормышка аша. 1942 елның 1 мартында, окоплар төзүне тәмамлап кайтуга, әле бүген дә яңгыраучы «Башмагым» музыкаль комедиясенең премьерасы була. Гадел Кутуй үзе дә кичләрен иҗат эшләре белән шөгыльләнә. Килгәч тә юлда күргән мәхшәрләр турында «Юл газабы» дигән шигырь яза. Күршесе куыксыз лампа кертеп биргәч, «Сукыр лампа» дигәнен иҗат итә. Менә бит күпме мәгълүмат бар. Соң булса да, уң булсын, дигән гыйбарәгә таянып, фидакарь хезмәт итүчеләрне мәңгеләштерү өчен, хәтерне чын-чынлап эшкә җигәргә генә кирәк. Шул уңайдан укучыларыбызга җиткерәсе бер үтенечем дә бар. Безнең авылда Җәвидә апаның: «Кайчандыр «Казан утлары» журналында окоп казуда катнашкан язучыларның шул хактагы әсәрен үзем укыдым», – дигәне бар. Әйтүе буенча, бу 50–60 нчы елларга туры килә. Электрон архивтан да эзләп карадым, язучыларга да мөрәҗәгать иттем. Әлегә табылмады. Белүчеләр, хәтерләүчеләр юкмы икән?

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

1942 елның 11 февралендә дәүләт комиссиясе әзер объектны кабул итеп алган. Монда танк үтмәсен өчен эшләнгән каршылыклар да, окоплар да, блиндажлар да булган. Барлыгы 392 күзәтү пункты, 98 яшерен ут ноктасы, 56 дзот, 419 землянка төзелгән. 1942 елның июлендә һәм 1943 елның августында Германиянең разведка самолетлары тарафыннан Казан һәм Яшел Үзәндәге объектлар төшереп алынган. Күрәсең, фашистлар Идел арьягындагы җирләрне «ялмап алу» турындагы планнарына һаман да өмет баглаганнар булса кирәк. Әмма бу вакытта безнең гаскәрләр инде ышанычлы адымнар белән Көнбатышка таба юл тоткан.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«КОЯШ» МАЛАЕ

Ул башкалар кебек түгел. Әтиәнисе аның диагнозын күптән оныткан. Бар эшне булдыра ул. Кирәк икән, карын көри, утынын кисә, суын ташый. Хәтта әнисенә кызлар эшендә дә булыша. Сүзебез Алмаз Минвәлиев турында.

– Мин улымның авыру буласын күңелем белән тойдым. Аллаһы Тәгалә сиздергәндер инде, – ди Алмазның әнисе Динара. – Кияүгә чыгып, авырга узгач та, кулыма Даун синдромлы балалар турында язылган журнал килеп керде. Ул чакта артык игътибар итмәдем. Мондый балалар да була икән, дидем. Хастаханәдә сакланып ятканда да шәфкать туташы никтер миңа үзенең Даун диагнозлы энесе турында сөйләде. Әң соңрак әллә нинди сәер төшләр күрдем. Янәсе, мин бала түгел, башка җанварга охшаган әйбер табам икән. Тик барыбер яхшыга өметләндем.

Динара Алмазын үз вакытында таба. Табиблар баланың авыру икәнен шундук әйтәләр. Әле син яшь, дип, авыру баласын калдырып чыгарга киңәш итүчеләр дә табыла. Алмазны башка бүлеккә күчереп, Динараны өенә кайтаралар. Ул китапханәгә барып, авыру хакында мәгълүмат туплый башлый. Ә күңеле белән баласының хастаханәдән чыгуын көтә. Хәл белергә килгән әнисе дә Динарага авыру баланы хастаханәдә калдырырга киңәш бирә. Әмма хастаханәгә барып, оныгын күргәч, әби фикере үзгәрә: «Кояш» малайны ташламыйбыз!

– Мин авыру хакында өйрәнгәч, үземне кулга алдым. Алмазны өйгә алып кайтып тәрбияли башлагач, җаваплылык артты. Ә ике айдан кабат балага узуымны белдем. Табибларның коты очты: монысы да авыру булачак! Аларны тыңламадым да. Ничек тә Алмазга игътибарны киметмәскә! Бар уем әнә шул булды, – ди Динара.

Минвәлиевләр Алмазны табибларга гына түгел, дәвалаучы әбиләргә дә күп йөртә. Мари Илендә яшәүче әби балага массаж ясый, Динарага да шуны өйрәтә.

– Әби безгә, балагызның гомере кыска булачак, Ходайдан сорагыз, догалар укыгыз, ул сезне ишетер, дип киңәш бирде. Мин гел сорадым. Улымны яшәтәсем килде. Догаларым кабул булды. Табиблар, йөри алмас, озак яшәмәс, дисә дә, Алмаз, шөкер, тәпи дә китте, сөйләшергә дә өйрәнде. Салават белән бергә үсте алар. Икесен тигез күрдем, – ди Динара.

Алмазга дүрт яшь чагында циркка бара алар. Шунда аренага роликта йөрүче аю баласы чыга. Әтиләре Илназ карап-карап тора да, аюны өйрәткәнне, без бу баланы өйрәтә алмабызмы, ди. Шул сүз җитә кала. Динара улын әкренләп эшкә тарта. Башта вак-төяк йомышлар куша. Аннары инде зур эшләрне ышанып тапшыра башлыйлар.

– Ул гел минем янымда. Салават үсеп җиткәч, Ильясымны таптым. Алмазга тагын иптәш булды. Үзе белән сөйләшеп, аңлатып тордым. Бакчага чыксам, Алмазны ияртәм. Бөтен эшне күреп өйрәнде. Энеләре эшли, ул да килеп кушыла. Ялкауланып тормый ул. Киресенчә, чишмәгә барсак та, мин барыйм әле, ди. Кызлар эшен дә белә. Идәннәрне ялт итеп юып куя. Алмаз бар эшне яратып эшли. Әле эш кушканга рәхмәт тә әйтә, – ди Динара. – Улыбыз укырга яратты. Мәктәптә чигәргә өйрәттеләр. Хәзер дә бу эшен яратып башкара. Әкренләп велосипедта, тимераякта, чаңгыда йөрергә өйрәнде. Бик оста йөзә. Кыскасы, Алмаз алдында киртәләр юк. Ул үзе теләп, баянда уйный башлады. Аны күреп, әтисе дә шаккатты. Илназ белән киңәшләштек тә, музыка мәктәбенә бардык. Укытучысы, әгәр укый белә икән, баянда уйнарга өйрәнәчәк, диде. Шулай итеп, музыка мәктәбен дә тәмамладык.

Алмаз атта та йөрергә өйрәнгән. Җәйләрен бик яратып җиләк җыя икән. Компьютер белән дә дуслашкан. Әллә нинди уеннар белә, ди әнисе. Газетадагы кроссвордларны да чишеп куя икән.

– Баланы кызганмаска кирәк. Минем күңелем тыныч. Улыбыз берүзе генә калган очракта да, тормыш итәргә әзер. Ашарга пешерергә өйрәттем. Аш та пешерә, йомырка да кыздыра. Газны да үзе кабызырга өйрәнде. Ишекне бикләп, утларны сүндереп чыгасын белә. Тик түләү эшләрен башкара алмый. Яше 23тә булса да, акылы 8 яшьлек баланыкы кебек шул аның. Шөкер, тормышта таянырлык энеләре бар, – ди Динара. – Алмазыбыз – өебезнең нуры, «кояшы». Күңеле изге аның. Барлык туганнары өчен өзелеп тора.

Гаилә башлыгы, җырчы Илназ Минвәлиев тә, баланы хезмәт белән тәрбияләргә кирәк, дигән фикердә.

– Әлегә кадәр эшләп үскән баланың бозылганы юк. Өч балабызга да бер төрле тәрбия бирдек. Безнең өйдә Алмазның диагнозы онытылды инде. Ул да энеләреннән бер җире белән дә ким түгел, – ди әтисе.

ӘНИЛӘРЕ СӨЕНЕП ЯТСЫН ИДЕ...

Гөлназ Маматкулованың шәхси архивыннан

Казанда яшәүче Гөлназ белән Руслан Маматкуловлар үзләренең ике баласы янына тагын ике ятимне сыендыра. Чит сабыйлар түгел – Гөлназның сеңлесенеке. Моннан ике ел элек әтиләре Рөстәм, бер ел элек әниләре Гөлшат, сабыйларын калдырып, мәңгелеккә күчкәч, алар ике дә уйламый балаларны үзләре ала.

Гөлшат белән Гөлназның яшь аермасы – бер ел. Әлмәт районының Яңа Кәшер авылында туалар. Гөлшат укытучылыкка укый. Шул елларда Рөстәм белән гаилә корып җибәрә. Бер-бер артлы Нурислам белән Айсылу туа. Бер-берләрен ярты сүздән аңлый торган булалар. Тик бәхетләренә күз тия. Матур гына яшәгәндә, Рөстәм авырып китә. Кинәт кенә температурасы күтәрелә. Берничә көн югары тора. Инде бар да узар, терелер дип көтсәләр дә, булмый. Рөстәм пневмониядән үлеп китә.

– Ирен югалткач, Гөлшат үзен кулга алырга тырышты. Алар яшәгән йорт иске иде. Сеңлем, кредит рәсмиләштереп, йорт төзи башлады. Авыл мәктәбендә рус теле дәресләрен укыта иде. Ике сабые хакына яши иде. Тик гомере генә озын булмады. Бар ачы хәсрәтне йөрәгенә җыйган икән сеңлем, – ди Гөлназ. – Гөлшат өйдән урамга чыкканда йөрәген тоткан да егылган да үлгән. Үләренә бер көн кала языштык. Икенче көнне төш вакытында аның вафаты турында җиткерделәр.

Гөлшатны җирләргә кайтканда юлда балалар язмышы хәл ителә...

– Туганымның балаларын ятим итмәгән өчен иремә рәхмәтле, – ди Гөлназ. – Ул барысын да бер минутта хәл итте. Документлар җый, балалар безнеке була, диде. Минем әни дә, кодагый да олы яшьтә. Аларга бала карау җиңел булмас иде. Гөлназны җирләгәннән соң, опека эшләренә керештек. Катлаулы процесс икән. Казан – Әлмәт арасын бик озак таптадык.

Быел Нурисламга – 8, Айсылуга 7 яшь тулган. Аларны бер-берләреннән аермаганнар, икесе дә 1 нче сыйныфка укырга кергән. Укытучылар сабыйларны мактый. Маматкуловларның үзләренең дә ике уллары бар. Берсенә – 20, икенчесенә – 16 яшь. Алар да шушы ике сабый янында бөтерелә. «Шушы балаларны кеше итеп үстерә алсак иде, – ди Гөлназ. – Балалар безгә апа белән абый дип эндәшәләр. Сабыйларның, күктә булса да, үз әти-әниләре бар. Алар сөенеп ятсын өчен, игелекле, тәрбияле балалар итеп үстерәсе иде. Кечкенә иңнәренә ятимлек ачысын күтәргән сабыйларга бар яратуымны бирергә тырышам. Аларга башка еларга язмасын!»

Сабыйларны сөендерергә теләүчеләр өчен: Гөлназның 89872387167 телефон номеры Саклык банкы картасына беркетелгән.

БЕЗ БЕЛМӘГӘН ИСӘНБӘТ

Соңгы берничә дистә елда галим Нәкый Исәнбәтнең исеме дә, хезмәтләре дә телгә алынмады, өч дистә ел дәвамында китаплары нәшер ителмәде. Аның сәбәпләрен төрлечә аңлаттылар. Фәкать язучы Ринат Мөхәммәдиев романы басылганнан соң гына ниндидер җанлану булып алды. Кем ул Нәкый Исәнбәт? Ни өчен аның шәхесенә карата мөнәсәбәт бер төрле түгел? Бу хакта без аның архивлары белән эшләүче галим Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА белән әңгәмә кордык. Сөйләшүнең сәбәбе дә бар: «Җыен» фонды «Шәхесләребез» сериясенең чираттагы томын Нәкый Исәнбәткә багышлады.

:: Миләүшә ханым, Нәкый Исәнбәтнең иҗади мирасы хакында бик күп еллар берничди хәбәр булмады, аның әсәрләре дә чыкмады диярлек. Моңа аның кызы Йолдыз Исәнбәтнең дә азмы-күпме йогынтысы бар. Сез – аның игътибарын һәм ышанычын яулаган бердәнбер галим. Шулай да, Йолдыз апа архивлар белән эшләү мөмкинлеген ни өчен беркемгә дә тапшырмаган?

– Нәкый Исәнбәтнең архивы минем өчен Әбугалисина мәгарәсе кебек, анда халкыбызның тарихы һәм мәдәнияте буенча бәяләп бетергесез гыйлем яшеренгән. Аларны бастырып чыгаруда галим-энциклопедист әле үзе исән чакта ук кыенлыклар кичергән. Проблемаларның нигезендә фән һәм иҗат әһелләренең көнчелеге ята. Ник дигәндә, Нәкый Исәнбәт төрле өлкәләр белән кызыксынган һәм төрле юнәлештә тирән, эзлекле эш алып барган. Галимнең вафатыннан соң, архивы кызы Йолдыз Исәнбәт кулына күчә. Дөрес, ул архивка беркемне дә якын китерми, үзе дә, кызганыч, хезмәтләрне әйләнешкә кертеп җибәрә алмый. Аның катнашында «Татар халык мәкальләре» һәм «Мыраубай батыр» әкияте генә басылып чыга. Сүз уңаеннан, ул чакта ук «пират» басмалар, әйтик, «Фразеологик сүзлек» дөнья күрә. Әлбәттә, бүген Нәкый Исәнбәтнең вафатыннан соң өч дистә ел дәвамында берничди китабы чыкмауда кызын гаепләп калдыру бөтен кешегә дә кулай. Ләкин бу – ялгыш фикер.

> Нәҗибә Исәнбәт, галимнең кызы белән киңәшләшмичә, үз вакытында Татар китап нәшриятына Исәнбәт кулъязмаларын илтеп бирә һәм алар анда урлана. Кемдер аның материалын, исемен телгә алып, ләкин чыганагын һәм куллану масштабын күрсәтмичә бастыра, ә кемдер барысын да үз хезмәте итеп күрсәтә...

Менә шуңа Йолдыз Исәнбәт кешеләргә ышанычын югалта. Атасы бит бу материалларны дәүләт ярдәменә таянмыйча, фәкать үз инициативасы белән дистәләрчә еллар дәвамында туплаган, аларга гомерен багышлаган.

:: Бүген ул мирас ни хәлдә? Нинди эшләр башкарылды?

– Йолдыз апа бик таләпчән кеше иде, моны аңларга һәм кабул итәргә кирәк. Мине аның белән бәхәсләшү файдасыз дип тә кисәтеп куйдылар. Бу да дөрес түгел. Холкы катлаулы булса да, ул аралашырга ярата, әмма наданлыкны, ялкаулыкны, игътибарсызлыкны һәм карьерага омтылуны җене сөйми. Шуңа һәр очрашу имтиханга әверелә, уңышлы тапшырасың икән, архивка юл ачыла, юк икән, барысын да яңадан башларга туры килә.

Архив галимнең беренче хатыны Гөлсем Исәнбәт тарафыннан системага салынган булган, чөнки ул бу эшнең җаен белгән. Ул бакыйлыкка күчкәч, бу эш тукталып калган, Нәкый ага, киң колачлы эш алып барганга, моңа вакыт таба алмаган. Нәҗибә апа исә һөнәре буенча рәссам һәм фәнни өлкәгә бик керешеп китә алмаган, күрәсең. Ләкин сәркатип эшен

Рамил Миннуллин

бик төгәл алып барган, кулъязмаларның бер өлешен гарәпчәдән кириллицага күчереп бастырган. Бу эшне бик җиңеләйтә, ләкин тикшерүне таләп итә.

:: «Җыен» фондының «Шәхесләребез» сериясендә дөнья күргән китапта моңарчы билгеле булмаган нинди мәгълүматлар бар?

– Иң әүвәл томлыкны формалаштыруны миңа тапшырган «Җыен» фондына бик зур рәхмәтемне белдерәм. Миңа басманың структурасын үзгәртеп, Нәкый Исәнбәтнең үзенә сүз бирергә насыйп булды. Ник дигәндә, язучының 70 яшенә автобиографик әсәрләре системага салынган булган инде. Йолдыз апа исә башка концепция яклы иде. Ул томның язучының башкорт чоры иҗатыннан башлануын теләде. Ә инде Аяз Гыйләҗевнең 6 томлыгы белән танышкач, ул минем концепциягә ышанды һәм без эшкә тотындык. Әлеге том галимнең иҗат биографиясендәге һәм, гомумән, безнең мәдәният тарихындагы «ак тап»ларны юкка чыгару максатыннан төзелде.

Укучы кайда чын дөреслек икәнен үзе ачыклар дип, без китапка башка даһиларның фикерләрен кертмәдек. Бары тик Бакый Урманчега гына искәрмә ясалды. Ник дигәндә, аның мәдрәсәдә инкыйлабка кадәрге укыту системасына багышланган тәфсилле мәкаләсе Исәнбәтнең энциклопедик сәләтен аңларга ярдәм итә. Китапта биографик өлештән кала, фәнни бүлек тә бар. Ул галим эшчәнлегенең чикләрен-офыкларын күзалларга ярдәм итә. Ләкин бу – булган материалларның бер мыскалы гына. Документларны сайлап алганда, мин Исәнбәт тормышындагы «шау-шулы кампанияләр»нең чыганагын аңлатып бирүне күз уңында тоттым. Чөнки без бу елларда галимнең оппонентлары тәкъдим иткән фаразлар белән генә яшәдек. Хәзер укучы нәтиҗәләрен үзе ясар инде. Исәнбәтнең хатларын сайлаганда да шул күзлектән карап эш иттем. Дистәләгән интервьюлардан исә саллыларын, васыять,

наказ булып яңгырардайларын сайлап алдым. Басма битләрендә ясалган аңлатмаларның бер өлеше минеке, бер өлешен Нәкый Исәнбәт үзе ясаган булган. Болар бар да искәртелгән.

:: Исәнбәт исеме соңгы елларда тискәре яктан да телгә алынды. Аның исемен каралту татар әдәбиятына ни дәрәҗәдә тәэсир итәчәк?

– Галимнең абруе тирәсендәге дулкынлану язучы Ринат Мөхәммәдиев романы басылганнан соң барлыкка килде. Мин анысына да рәхмәтле. Әлеге әсәр тумаса, мин Нәкый Исәнбәт шәхесе һәм иҗаты белән кызыксынып китмәгән дә булыр идем. Гомумән, бу юнәлештәге эшчәнлегем барысы өчен дә көтелмәгәнчә булды. Ләкин биредә үзенә күрә эзлеклелек тә бар: галим архивы белән эшләүгә мине Аяз Гыйләҗев әзерләде. Аның Ибраһим Сәлаховка язган хатын үземә наказ, васыять итеп кабул иттем. Бөтен кешегә мин ялгызым эшлим кебек тоела. Һич тә алай түгел. Миңа язучы, галимнәр консультация бирә.

> Дөресен әйтик, Исәнбәт архивындагы бик күп нәрсәгә безнең тешебез үтми, фәкать төрле өлкә галимнәре белән бергәләп кенә без ниндидер нәтиҗәгә ирешәбез.

Үз эшемә бик җаваплы карыйм, шуңа ашыкмыйча эшлим, мәгълүматны каткат тикшерүгә бик күп вакыт сарыф итәлә. Бу җәһәттән ирем – тарихчы Айдар Хәбетдинов ярдәм итә. Архивта эшләүгә бөтен буш вакыт китә.

:: Исәнбәтнең тагын нинди хезмәтләре дөнья күрергә мөмкин?

– Якын арада Нәкый Исәнбәтнең татар мифологиясе, халык ышанулары һәм медицинага кагылышлы хезмәтләрен редакцияләп, әзерләргә ниятлим. Әлеге китап укучыларда кызыксыну уятыр дип өметләнәм. Ел дәвамында Нәкый Исәнбәтнең Тукай, Галимҗан Ибраһимов белән мөнәсәбәтләре турында мәкаләләр бастырдым. Заманча әдәбиятта Исәнбәт образын анализладым. Галимнең иҗатын Россиядә генә түгел, чит илдә дә таныту юнәлешендә эш алып барыла. Аңа карата корылган блокада өзелде дип әйтергә була. Хәзерге вакытта Исәнбәт турында дөньяда (Төркия, Венгриядә) булган мәгълүматлар, туплап, системага салынды. Германиядә, Скандинавия илләрендә дә фәнни эшләр басылганлыгы ачыкланды. Ләкин аларны әлегә файдалану мөмкинлеге юк.

Кайчак миңа югарыдан кемдер, кулымны тотып, гыйлем ишекләрен ачып кертә сыман тоела. Миңа исә эккерсез хезмәт итәргә, татар халкының шанлы тарихын баетырга кала. Шушы юлга күндергәне өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА, филология фәннәре кандидаты:

– Бүген Йолдыз Исәнбәтне искә алганда, аның әтисе Нәкый ага Исәнбәтне телгә алмый китә алмыйбыз. Ул – Йолдыз апаның галим, мөгаллим, татар милләтенә бирелгән шәхес буларак тәрбияләнүендә иң мөһим рольләрне башкарган кеше. Милли мәдәнияткә бәйле нинди генә дискуссия кузгалса да, Йолдыз апа, фикерен куәтләр өчен, әтисе әйткән сүзләрне китерә иде. Шунысы гаҗәп: Нәкый аганың фикерен ул халык җырына, әдәбиятының шигырь төзелеше, фольклор әсәрләре жанрларына бәйле дә әйтер иде. Мин моңа гаҗәпләнеп, «Нәкый ага боларның барын да әйттеме икән?» дигән сорауны үземә еш бирә идем. Узган 2021 елда «Җыен» фонды оештырган «Шәхесләребез» сериясендә Нәкый Исәнбәт биографиясенә кагылышлы җыентыгын басмага әзерләгәндә кулдан кичкән хезмәтләрен, мәкаләләрен уку барышында әлеге соравыма җавап бирелеп кенә калмады, соклану, гаҗәпләнү кебек кичерешләр белән уралган яңа фикерләр туды.

Мәсәлән, җыентыкта урын алган материаллар татарларга Нәкый аганы энциклопедист буларак кына түгел, ә татар мәдәниятенең милли нигезләре закончалыгын ача алган әзерлекле галим буларак таныта торганнардан булып чыкты. Аннан, бу җыентыкта бирелгән әсәрләр аркылы татар этнографиясендә моңа кадәр игътибар ителми килгән сәүдәгәрләр тормышына бәйле этнографик материалларны да, мәдрәсәдә белем бирү системасының нәтиҗәлелеген дәлилләүче фактларны да, ХХ гасыр башында татар балалары өчен ачылган рус мәктәпләрендәге уку-укыту торышын да күз алдына китереп була. Кыскасы, бирелгән бик күп материал – менә дигән фәнни чыганак. Тагын бирелә әлләни кадәр әзәрләкләүгә, ялалар ягылуга дучар ителгән Нәкый ага биографиясенә бәйле шактый күп документлар китерелә. Алар үз чиратында милли мәдәниятебезнең бик күп ак таплар калдырган чоры – 1930 нчы еллар башындагы процессларга объектив ачыклык кертә ала торганнардан, ә алар үз чиратында әдәбият тарихына башкача күзлектән карауны таләп итәләр. Җыеп әйткәндә, җыентык чын мәгънәсендә татар әдәбияты, мәдәниятенә бәйле серләр сандыгына үзенчәлекле ачкыч ролен уйный, ләкин ачкычны әле туры китерә дә белергә генә кирәк шул.

2022 елның маенда Идел Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу дәүләти, тәкъваи вә иҗтимагый дәрәҗәдә киң күләмдә билгеләнеп үтәчәк. Бу күренекле вакыйга әдәбият, мәдәният, сәнгать әһелләренә дә иҗат омтылышы өстәде. Гомумән, Болгар темасы, дини багланышлар темасы буенча татар әдәбияты – зур тәҗрибә туплаган әдәбият. Кол Гали, Котб, Кол Шәриф, Гаяз Исхакый, Нәкый Исәнбәт, Әбрар Кәримуллин, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла, Марсель Галиев, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Ркаил Зәйдулла, Солтан Шәмси... кебек язучыларыбызның иҗаты – моңа ачык дәлил. Алар арасында күренекле прозаик Марат Әмирханов та бар.

Газета укучыларыбызга аның Болгар чорын тасвир иткән яңа романыннан өзекләр тәкъдим итәбез.

МАРАТ ӘМИРХАНОВ

ШӘҺРЕ БАНУ

922 ел, май ае, уникенче көн.

Кышкы озын йокыдан соң табигатьнең инде тәмам уянып, чәчәккә бөреләнгән илаһи матур чагы. Ялан-кырларны узган елгы кура калдыкларын ерып чыккан түбәтәйдәй купшы үлән патшалыгы үз кочагына алган. Яшел күлмәкләре бик килешле. Куакларда кошлар куанышa, зәңгәр күктә кояш елмая.

Кая карама, яз, яз, яз!

Шулвакыт искәрмәстән генә кыйбла ягыннан өрфә җил җанланып китте дә үлән яфракларын, агач ябалдашларын, чатыр япмаларын иркәләп сыйпап узды. Шуннан соң ук тау читеннән кош оясы кадәрле генә бер болыт калкып чыкты. Килә-килешкә ул күзгә күренеп, ачы камырдай кабара-кабара, мизгел эчендә күкне биләп алып, чакма ташыдай сызып җибәрде: әүвәл яшен камчысы елкылдады, аннан шартлау тавышы яңгырады.

– Әссәламегаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәтүһү, – дип сәламләде илче мәликне. – Ходай хәерле падишаһлык насыйп итсен.

– Вәгаләйкүмәссәлам, – дип җаваплады хаким, – бирахмәтикә йәә әрхәмәррахимин.

Кыска вакытлы бу очрашу Мораса елгасы янында урнашкан шул ук исемдәге авыл тирәсендә, табигатьнең гаҗәеп матур урынында, киң тугайда үтте.

– Сезнең өчен гөмбәзле чатырлар кордырдым, ашагыз, эчегез, әйбәтләп ял итегез, – диде Алмыш мәлик. – Аллаһы рәхмәте белән, җомга көнне хуҗам һәм туганым мөхтәрәм әл-Мөгътәдир биллаһ Әбел-Фазыл хәлифә хәзрәтләренең юлламасын кабул итү тантанасына җыелырбыз. Ике ил арасындагы элемтәләребез турында да, сезнең алдагы гамәлләрегез турында да шунда фикер алышырбыз.

Шифалы, җылы, мәрхәмәтле ләйсән яңгыр башланды.

Болгарлар ләйсән яңгырны Рәхмәт яңгыры дип йөртә. Фаразларынча, ләйсән суын бака йотса – энҗегә, елан йотса, агуга әйләнә икән.

Яңгыр тамчылый башлауга, Алмыш мәлик атынның җиргә сикереп төште дә үлән өстеннән тәгәрәп китте. Аңа даирәсе иярде.

Сөбханалла!

Ләкин тамаша озакка сузылмады, күзәтүче угланның көр тавышы яңгырады:

– Киләләр!

Шушы хәбәрне генә көткәндәй, җилбикә болытны тау артына куып алып китте. Кояш янә елмаеп, җиргә нурларын сипте.

Сөбханалла!

Күп тә үтми, ашъяулык җәелгәндәй тигез үзәнлек очында «Болгар сәяхәте» теземе күренде. Иң алда – илче Сәнсән әр-Рәсиби. Бик күркәм бурлы атка атланган. Бурлы шушындый тамашалар өчен өйрәтелгән иде, күрәсең, биеп кенә килә.

Илче киң саргылт билбау белән уратып алынган көрәнсу җиләннән иде. Башында алсу өслекле чалма, аякларында бизәкле кызыл читек. Ни өчендер, илчегә хас булмаганча, биленә кылыч та аскан.

Аннан бер-ике адымга гына калышып, илчелекнең сәркәтибе Әхмәд ибне Фазлан килә. Ул башкалардан аерылып тора иде. Киеме дә үзгә. Өстендә карасу бишмәт, кызыл күлмәк, башында яшел камаулы кызгылт башлык. Биле буш, кылыч та, хәнҗәр дә такмаган. Аның урынына, бармакларында алтын-көмеш балдак-йөзекләр ялтырый.

Ибне Фазлан ерактан ук Алмыш мәликне күз уңына алды. Затлы дирбияләргә уралган Тимер-күк толпарын да, хакимнәргә генә тиң кыйммәтле кием-салымын да ошатты. Падишаһ шулай күрекле булырга тиеш иде ул.

Каләмкәш бит, күңеленә аның сурәтләмәсен дә беркетеп куйды. Мәлик киләсе буыннарга шушы сурәтләмә буенча барып ирешәчәк. Менә ул: «Алмыш – ярыйсы гына тулы гәүдәле, инде корсак та үстерә башлаган урта яшьләрдәге боеручан бер хакимдер».

– Сөбханалла, мәлик, – диде илче Сәнсән әр-Рәсиби, – без сезгә бик рәхмәтлебез.

Болгарның алдагы өч көне намазлык өстендә узды. Меңләгән мөэмин-мөселман Аллаһыдан киләсе изге җомганың аяз, җил-яңгырсыз кояшлы матур көн булып тууын үтенеп, догага оеды. Алмыш үзе дә күп вакытын мәчеттә уздырды.

Бу эчкерсез вә ихлас дога-теләкләр җылы шытым бирде. Көн тыныч вә дымык, гыйззәтле вә нәфис иде. Иртә таңнан олысы-кечесе тантана буласы урынга ашыкты. Бераздан үзәнлектә алма төшәр урын да калмады, халык мыж. Читтәгеләр ат өстендә, тау башы да чуп-чуар.

Тәртип саклау Хәсникәмал яугирәләр өстендә. Күрәсең, мөслимәләргә ышаныч зуррак иде. Хак, кыз-хатынның сиземләге ау төлкесе сиземлегенә тиң бит ул, кемнең ни уйлаганын, ниятен үз-үзен тотышыннан ук тоеп-белеп ала. Падишаһ һәм шәрәфле кунаклар килгәнче, әнә берничә тынгысыз бәндәне озатып та өлгерделәр. Шым булды гавам.

Алмыш мәлик тантананы үзе ачты. Ул, ни сәбәпледер, бизәкле-чуклы киемнән иде. Мул гәүдәсенә юка-җиңел күлмәкыштан килешә икән үзе.

Сүзләре дә шушы бизәкле киемнәре кебек бизәкле һәм килешле иде.

– Рәхимле вә шәфкатьле Аллаһының исеме белән, – дип башлады ул нотыгын, – хисапсыз мактау һәм макталу кодрәте Аллаһы Тәгалә хозурына булсын. Безне адәм итеп яратты, туры юлга күндерде. Мин иманга килүем, мөселман булуым белән чиксез горурланам. Күркәм йөзле, хак сүзле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләнең салават-сәламнәре булсын. Шушы изге юлдан барып, барча мөселманнарны Иман нурында коендыручы Габбасия хәлифәләреннән Әмирел-мөэминин әл-Мөгътәзыйд хәлифә хәзрәтләренә дә эчкерсез ихтирам вә сәламнәремне җиткерәм.

Ул озын һәм киң җиң эчендәге кесәсенә тутырган көмеш тәңкәләрне ерактан килгән кунаклар өстенә сипте.

– Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ!

Мәйдан уртасына илче Сәнсән әр-Рәсиби чыгып басты. Кулында байрак.

– Данлы Болгар дәүләтенең лаеклы падишаһы мөхтәрәм белеквар Силки ибне Алмыш хәзрәтләре! Мөселман дөньясының олуг башлыгы, Габбасия мәмләкәте хәлифәсе әл-Мөгътәдир сине үз канаты астына ала, – диде тавышына тантаналы төсмер бирергә тырышып, – шул игелекле ниятенең билгесе итеп, Дәүләтебезнең ошбу байрагын кабул итеп ал.

Алмыш байрак алдында тезләнеп, аны битенә япты. Шунда ук бизәкле камзулларын салдырып, аңа Габбасия хәлифәтенең әһле йөзе саналган махсус кара чапан кидерделәр, башына чалма урадылар.

Ә аннан?

Сыпра сынлы ерау
Тора биреп тулгайдыр,
Тулгай биреп сырнайдыр,
Боты савырлы көрән ат,
Ботка тартып менәр ат.

Йосыф пәйгамбәрдәй мөкәммәл буйсынлы ике гайде гази мәшһүр Гали имам Дөлдөле шикелле озын аяклы, җиңел гәүдәле җилдәй җитез толпар-атны ефәк тезгененнән тотып, мәйдан әйләнделәр дә мәлик каршына килеп туктадылар.

Кыйган камыш колаклы,
Тустыгандай тояклы,
Арт өркәчле дөядәй,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле,
Чапкан чакта җил җитмәс,
Табаны ялпак Тарлан буз.

– Аргамак Мөгътәдир биллаһның шәхси бүләге, – диде илче, – үз утарыннан.

– Афәрин!

– Инде, хөрмәтле болгарлылар, – дип дәвам итте илче, – пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең ыру дәвамчысы әл-Мөгътәдир хәлифәнең хатындагы изге җөмләләрне тыңлап, әһвале рухия күңелләрегезне хушландырыгыз.

Хатны илчелекнең сәркатибе Әхмәд ибне Фазлан укыды. Тавышы көчле һәм аһәңле иде, тын да алмый тыңладылар.

– Аллаһудан башка иләһә-мәгбуд юк. Аллаһу әкбәр!

Дәррәү намазга бастылар.

Намаздан соң чалмалы Алмыш мәлик үзенең шәрәфле карарын җиткерде.

– Мөхтәрәм өммәтем, мин бүгеннән үз исемемнән ислам динен дәүләт дине дип игълан итәм, – диде. – Аллаһы рәхмәте белән, Бөтенболгар җыены җыячакбыз һәм җыен минем бу карарымны хуплар, дип ышанам.

– Аллаһу әкбәр!

Үзән бертавыштан җаваплады.

– Аллаһу әкбәр!

Хаким сүзендә торды, нәкъ ике айдан соң Бөтенболгар җыенында ислам динен кабул итүне инде рәсми төстә бөтен халык исеменнән игълан итте.

Тарихи белешмә:

Болгарлар Хәлифәттән үз илләренә ислам диненә өндәүчеләрне, мәчет һәм кальга төзелешендә ярдәм итәрлек кешеләр җибәрүне сорый. 922 елның уртасында Җаушир (мә) елгасы ярларында (хәзерге Чистай районының Яуширмә авылы янәшәсендә. Бүген анда «Ханнар буасы» дип аталган урын бар) җирле аксөякләрнең – болгар кабиләләре башлыкларының Алмыш хан җитәкчелегендә корылтае була. Анда ислам дине Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми дәүләт дине дип янә бер тапкыр игълан ителә.

Дәвамы бар >

Шигърият

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

КИЧ

Алсу кояш карап тора
Яфраклар арасыннан.
Тып итеп өзелер кебек
Өлгергән алма сыман.

Койма башына малайлар
Утырганнар тезелеп.
Күзәтәләр шул алманы:
Кайда төшәр өзелеп?

Офыктагы карурманга
Өзелеп төшәр менә.
Кара урман керпе кебек
Эләчәк энәсенә...

Аргы якка сикерәләр –
Үкенечкә калмасын! –
Алып чыгыйк бер, булмаса,
Салих бабай алмасын!..

1978

***

Көз сиңа дүрт алма биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Икесен битеңә куй син,
Икесен – күкрәгеңә».

Кыш сиңа аклыгын биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Яртысын тәнеңә сип син,
Яртысын – күңелеңә».

Җәй сиңа эсселек биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Беразын куеныңа сал,
Калганын – йөрәгеңә».

Яз сиңа мине биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Бәхетле ит бу егетне,
Сөяр ул сине генә».

1980

***

Син эзләмә китапханәләрдән.
Анда юк ул. Миндә. Кил, табын.
Сиңа бөек шагыйрь булсам да мин,
Юк «Мәхәббәт» дигән китабым.

Зур томнарга сыймый минем сөю,
Язганым юк, укыйм үземнән.
Кил җаныма, сөю шигыремне
Төннәр буе укы күземнән.

1981

ИШЕК ТӨБЕНДӘ ӘЙТЕЛГӘН СҮЗ

Исәнме, исәнме, иркәм!
Мин килеп җиттем менә.
Дию урлап киткән сине
Шәһәр дигән иләнә.

Эзләп килдем. Кырыс агай
Өеңә өйрәтте юл:
– Вино кибетен уз, энем,
Ресторан янында ул...

Килә-килә сорадым мин
Сумка тоткан ханымнан:
– Маникюр залын уз, егет,
Эзлә базар яныннан...

Бераз килгәч эндәштем мин
Сөрмә күзле бер кызга.
– Чәчәк кибетен табыгыз,
Шушында йөртыгыз да...

Рәхмәт кызга, эзләп таптым.
Әкият кебек менә.
Әкияттәге егет кебек,
Коткарырга килдем сине...
Ә син... көләсең генә...

1981

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 майга кадәр газетага язылучылар арасында
ТАНДЫР һәм ӘФГАН КАЗАНЫ
уйнатабыз

П2435
җомга саны
488 сум 10 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1099 сум 32 тиен

Май ае өчен квитанцияләр 2022 елның 8 июненә кадәр кабул ителә. Бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июленә хәтле дәвам итә. Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru
16+
Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат
тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

Корыч казаннар, әфган казаннары, мангал, казаннар өчен мичләр. Безнең кибеттә табигатьтә ризык әзерләү өчен бөтен төр товарлар да бар.
тел.: +7-905-020-00-39
«Мир казанов 116», ТР, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 100 нче й., элмә тактасы – «ЭКОМАРКЕТ»
Реклама



6 май санында чыккан сканвордның җаваплары

Горизонталь буенча: Зариф, да, исәп, мамонт, аорта, обер, капа, пасха, Азин, Ровно, енка, Отс, оратор, арпа, кип, колун, теш, курач.

Вертикаль буенча: видеокамера, баз, адәм, епископ, рапа, ран, ара, фотоаппарат, ору, Но, трос, Воркута, хант, инеч, Сара, Осип.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Рус-төрек сугышы ничәнче елларда була?
А) 1700–1721;
Б) 1661–1662;
В) 1677–1681.

2 Фәрит Бикчәнтәев – ул...
А) сәнгать мәктәбе җитәкчесе;
Б) Камал театрының баш режиссеры;
В) КФУ мөгаллиме.

3 Бу елны «Сәйяр» театр труппасыннан С.Гыйззәтуллина-Волжская китә һәм Уфада яңа труппа төзи.
А) 1922;
Б) 1800;
В) 1912.

4 Танылган волейболчы Екатерина Гамова карьерасын ничәнче елда туктата?
А) 2016 ел;
Б) 2020 ел;
В) 2005 ел.

5 «Сүздән тора дәвам, Сүздән тора,
Кеше заты синең сүзең белән
Китеп бәхет тапкан эздән тора –
Дәвам бездән тора».
Бу шигырь юлларының авторы кем?
А) Мөдәррис Әгъләмов;
Б) Галимҗан Баруди;
В) Роберт Миңнуллин.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) В; 4) А; 5) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 265

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+